# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 10*
*октябрь*
*2015*
*(I өлеш)*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ
СОВЕТЫ РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
2015

ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ:
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

Формат 60х84$^{1}/_{16}$. Тираж 32 экз.

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 2015

Эчтәлек

# I

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

1012. «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» Татарстан Республикасы Законының 4[1] статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы*........................6

1013. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәреш кертү турында» *Татарстан Республикасы Законы* .......7

1014. «Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы*........................................................9

1015. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы*................................................ 10

1016. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы*.................................................... 16

1017. «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы*............. 19

1018. «Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү ча-

ралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы*............................................ 35

1019. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы*............................... 36

1020. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы*............................................ 37

1021. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..... 39

1022. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 21 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы*............................... 41

1023. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы*............................... 42

1024. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Законы*....... 43

1025. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы*.............................................................. 44

1026. «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ...... 45

1027. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ........................... 50

1028. «Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ......54

1029. «Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында» *Татарстан Республикасы Законы* ........................... 59

1030. «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты проектын һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын төзү һәм раслау үзенчәлекләре турында» *Татарстан Республикасы Законы*................................................ 66

1031. «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ...... 68

1032. «2016 елга Татарстан Республикасында муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» *Татарстан Республикасы Законы* ................ 77

1033. «2016 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» *Татарстан Республикасы Законы*................................................ 85

1034. «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ........................... 98

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1012. «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» Татарстан Республикасы Законының 4[1] статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4[1] статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2011, № 12 (I өлеш); 2013, № 1), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Муниципаль норматив хокукый актта Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль берәмлек уставына каршы килә торган нигезләмәләр ачыкланганда, вәкаләтле органның эксперт бәяләмәсе, аны төзегән көннән алып җиде эш көне эчендә, мондый актны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органына (җирле үзидарәнең вазыйфаи затына), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм прокуратура органнарына җибәрелә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 7 октябре
№ 66-ТРЗ



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1013. Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле 33[3] статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«33[3] статья. **Дәүләт яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен арендага бирү**

1. Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген, шул исәптән дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлеген, яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе, Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәсе нигезендә җир кишәрлеге юридик затларга социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен бирелгән очракта, күрсәтелгән объектларның, инвестиция проектларының әлеге статьяда билгеләнгән критерийларга туры килү шарты белән, торглар үткәрмичә төзелә.

2. Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар стратегик планлаштыру документларында, Татарстан Республикасының, муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсеш программаларында билгеләнгән өстенлекләргә һәм максатларга туры килсә һәм мәдәният, сәнгать, кинематография, спорт, төзекләндерү, сәламәтлек саклау, мәгариф һәм тәрбия эше, социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү, коммуналь хуҗалык, халыкка көнкүреш хезмәте

күрсәтү объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, күпкатлы һәм (яисә) җир асты машина кую урыннары (парковкалар), күпкатлы гаражлар булып торса, җир кишәрлеген мондый объектларны урнаштыру өчен бирү рөхсәт ителә.

3. Җир кишәрлеген масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатларында бирү масштаблы инвестиция проекты түбәндәге критерийларның берсенә туры килгән очракта рөхсәт ителә:

1) эш урыннары булдыру яисә аларның санын арттыру;

2) инвестицияләрнең күздә тотыла торган күләменә таләп;

3) Татарстан Республикасы территориясендә түләнә торган салымнардан еллык керемнәрнең артуы;

4) намуссыз застройщиклар гамәлләреннән (гамәл кылмауларыннан) зыян күргән гражданнарның — күпфатирлы йортлар төзүдә өлешле катнашучыларның хокукларын яклау чараларын күрү өчен шәхси торак йортлар һәм (яисә) күпфатирлы йортлар төзү.

4. Әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән критерийларның сыйфат һәм (яисә) сан күрсәткечләре Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

5. Әлеге статьяда каралган нигезләр буенча җир кишәрлеге алуда кызыксынган юридик зат Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына яисә ул вәкаләт биргән органга мөрәҗәгать итә, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектның, масштаблы инвестиция проектының әлеге статьяда күрсәтелгән критерийларга туры килүе турында документлар тапшыра. Юридик затка җир кишәрлеге бирү турындагы тәкъдим социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектның, масштаблы инвестиция проектының әлеге статьяда күрсәтелгән критерийларга туры килүе турында дәлилле бәяләмә белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасы Президентына кертелә. Юридик зат белән җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы яисә җир кишәрлекләре белән эш йөртүгә вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан җир турындагы законнар нигезендә билгеләнгән тәртиптә төзелә.

6. Юридик зат тарафыннан әлеге статьяның 5 пунктында каралган документларны бирү тәртибе, аларның исемлеге, карау тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.



**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып 30 көн эчендә шушы Законның гамәлгә ашырылуын тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 7 октябре
№ 67-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1014. «Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» 2002 елның 15 октябрендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 10; 2003, № 9 (II өлеш); 2013, № 4 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә:

а) 6 пунктта «Россия Федерациясе гражданлыгы» сүзләре алдыннан «җәмәгатьчелек вәкиленең» сүзләрен өстәргә;

б) 7 пунктта «җәмәгатьчелек вәкиленә карата» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 11 һәм 12 пунктлар өстәргә:

«11) Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясе утырышларында җәмәгатьчелек вәкиленең нигезле сәбәпләрсез дүрт ай дәвамында булмавы;

12) җәмәгатьчелек вәкиленең үз абруена тап төшерә торган гамәл кылуы.»;

2) 1[1] өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 7 октябре
№ 68-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1015.«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:
а) 3 өлештә:
2 пунктта «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең республика программаларын» сүзләрен «кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын)» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү буенча муниципаль программаларга» сүзләрен «кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган муниципаль программаларга (ярдәмче программаларга)» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 13 һәм 14 пунктлар өстәргә:

«13) товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу планнары проектларының, инновацияле продукцияне, югары технологияле продукцияне, дару чараларын сатып алу планнары проектларының, мондый планнарга кертелә торган үзгәрешләр проектларының, «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән конкрет заказчыларның кече һәм урта эшкуарлык субъектларының сатып алуда катнашуын күздә тоткан Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә оештыру һәм гамәлгә ашыру;

14) товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу планнарының, инновацияле продукцияне, югары технологияле продукцияне, дару чараларын сатып алу планнарының, мондый планнарга кертелгән үзгәрешләрнең, кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан сатып алу турында еллык хисапларның, «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән аерым заказчыларның инновацияле продукцияне, югары технологияле продукцияне сатып алу хакында (кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан сатып алу өлешендә) еллык хисапларының кече һәм урта эшкуарлык субъектларының сатып алуда катнашуын күздә тоткан Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвенә мониторинг ясауны Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә оештыру һәм гамәлгә ашыру.»;

б) 5 өлештә «кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүнең республика программалары» сүзләрен «кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программалары (ярдәмче программалары)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 статьяда:

а) 2 өлешнең 2 пунктында «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең республика программаларын» сүзләрен «кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Вәкаләтле орган кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын) гамәлгә ашыруга бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы була. Вәкаләтле орган кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын) гамәлгә ашыру кысаларында товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларны гамәлгә ашырганда дәүләт заказчысы була.»;

в) 4 өлештә «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең федераль, республика һәм муниципаль программаларын» сүзләрен «Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Россия Федерациясе дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын), Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын) һәм муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны)» сүзләренә алмаштырырга;

г) 5 өлештә «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең республика программаларын» сүзләрен «кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын)» сүзләренә алмаштырырга;

3) 8 статьяда:

а) 1 өлештә «микрофинанс оешмаларын» сүзләрен «кече һәм урта эшкуарлык субъектларына микрозаемнар бирүче һәм эшкуарлык эшчәнлеген, шул исәптән урта һәм кече бизнесны үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белән килештерелгән Россия Федерациясе Үзәк банкының норматив актында билгеләнгән критерийларга туры килүче микрофинанс оешмаларын (эшкуарлыкны финанслаучы микрофинанс оешмаларын)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү буенча республика программаларын һәм муниципаль программаларны» сүзләрен «кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган тиешенчә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын) һәм муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны)» сүзләренә алмаштырырга;



4) 9 статьяда:

а) 1 өлешнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын) һәм муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) гамәлгә ашыру максатларында кабул ителә торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән шартларга туры килә торган кече һәм урта эшкуарлык субъектларының күрсәтелгән программаларда (ярдәмче программаларда) бертигез дәрәҗәдә катнашу мөмкинлеген булдыру;»;

б) 3 өлештә «җитештерүне һәм» сүзләреннән соң «(яисә)» сүзен, «чыгаруны һәм» сүзләреннән соң «(яисә)» сүзен өстәргә;

в) 4 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) гариза бирүче кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Россия Федерациясе дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын), Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын) һәм муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) гамәлгә ашыру максатларында кабул ителә торган Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән документларны тапшырмаса яисә дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырса;»;

3 пунктта «шундый ярдәм күрсәтү» сүзләреннән соң «(аны күрсәтү шартлары тәңгәл килә торган ярдәм, моңа ярдәмнең рәвеше, төре һәм аны күрсәтү максатлары керә)» сүзләрен өстәргә;

5) 10 статьяда:

а) 1 өлештә «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең республика һәм муниципаль программаларында» сүзләрен «кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программаларында (ярдәмче программаларында) һәм муниципаль программаларда (ярдәмче программаларда)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «законнарда билгеләнгән шартларга, кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең федераль, республика һәм муниципаль программаларында каралган шартларга» сүзләрен «Федераль законның 4 статьясында билгеләнгән шартларга һәм кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Россия Федерациясе дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын), Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын) һәм муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) гамәлгә ашыру максатларында кабул ителә торган Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган шартларга» сүзләренә алмаштырырга;

6) 11 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программалары (ярдәмче программалары)»;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү шул исәптән кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программалары (ярдәмче программалары) нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

в) 2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

г) 3 өлештә «Программаларны» сүзен «Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын)» сүзләренә алмаштырырга, «закон» сүзе татарча текстта үзгәрешсез кала;

7) 12 статьяның 6 өлешендә «республика программалары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 13 статьяда:

а) 1 өлештә «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү буенча республика программалары һәм муниципаль программалар» сүзләрен «кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программалары (ярдәмче программалары), муниципаль программалар (ярдәмче программалар)» сүзләренә алмаштырырга;



б) 4 өлешнең 1 пунктында «мөлкәт исемлеген» сүзләреннән соң «ел саен – агымдагы елның 1 ноябренә кадәр мондый исемлеккә Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен өстәп» сүзләрен өстәргә;

9) 14 статьяның 1 пунктында «законы» сүзе татарча текстта үзгәрешсез кала;

10) 15 статьяның 3 өлешендә:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Россия Федерациясе дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын), Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын), муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) гамәлгә ашыру турында;»;

б) 9 пунктта «(икътисадый, хокукый мәгълүмат, статистика, җитештерү-технология мәгълүматы, маркетинг өлкәсендәге мәгълүмат) мәгълүмат» сүзләреннән соң «, шул исәптән Федераль закон нигезендә эшләүче кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү корпорациясе эшчәнлеге өлкәсендәге мәгълүмат белән» сүзләрен өстәргә;

11) 20 статьяның 3 пунктында «федераль, республика программаларын» сүзләрен «дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын)» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 7 октябре
№ 69-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1016. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:
а) 1 пунктта «ачык» сүзен төшереп калдырырга;
б) 2 пунктның икенче абзацында «ачык» сүзен төшереп калдырырга;
в) 6[1] пунктта «рәсми матбугат басмасы һәм» сүзләрен төшереп калдырырга, «сайт» сүзеннән соң «(алга таба – «Интернет» челтәрендәге рәсми сайт)» сүзләрен өстәргә;
г) 7 пунктта «массакүләм мәгълүмат чараларында һичшиксез басылып чыгарга» сүзләрен «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларда һичшиксез урнаштырылырга» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяның 3 өлешендәге 7 һәм 9 пунктларында «ачык» сүзен төшереп калдырырга;

3) 4 статьяның 2 һәм 2[1] өлешләрендә «ачык» сүзен төшереп калдырырга;

4) түбәндәге эчтәлекле 6[1] статья өстәргә:

«6[1] статья. **Бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын тапшыру**
Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына) кертелгән унитар предприятиеләр, акционер җәмгыятьләр һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр башкарма хакимиятнең вәкаләтле органына еллык бухгалтерлык



(финанс) хисаплылыгын, Россия Федерациясенең бухгалтерлык хисабы турындагы законнарында анық мәҗбүри нөсхәсен, кварталлык, ярты еллык, тугыз айлык арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын тапшыру өчен билгеләнгән срокта, әлеге хисаплылыктагы мәгълүматны «Интернет» челтәрендәге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән рәсми сайтта урнаштырып, хисап чоры тәмамланган көннән алып утыз көннән дә соңга калмыйча тапшыра.»;

5) 8 статьяның 2 өлешендә:
а) унберенче һәм уникенче абзацларда «ачык» сүзен төшереп калдырырга;
б) унбишенче абзацта «ачык» сүзен төшереп калдырырга;

6) 9 статьяда:
а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы), дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлар, күрсәтелгән мөлкәтне сату турында һәм аны сату нәтиҗәләре хакында мәгълүмати хәбәрләр, дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турында еллык мәгълүмат «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән рәсми сайтта, шулай ук торглар үткәрелү турында мәгълүмат урнаштыру өчен «Интернет» челтәрендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән Россия Федерациясе рәсми сайтында (алга таба – «Интернет» челтәрендәге сайтлар) урнаштырылырга тиеш.»;
б) түбәндәге эчтәлекле 1[1] өлеш өстәргә:
«1[1]. Дәүләт мөлкәтен сату турында, аны сату нәтиҗәләре хакында мәгълүмати хәбәр шулай ук дәүләт мөлкәтен сатучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырыла.»;
в) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. «Интернет» челтәрендәге сайтларда урнаштырыла торган дәүләт мөлкәтен сату турында мәгълүмати хәбәрдә, шулай ук дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру алыш-бирешләренең нәтиҗәләре турында мәгълүматта хосусыйлаштыру турындагы федераль законнарда билгеләнгән белешмәләр күрсәтелергә тиеш.»;
г) 3 өлештә «рәсми матбугат басмасында бастырып чыгарылырга, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;
д) түбәндәге эчтәлекле 3[1] өлеш өстәргә:
«3[1]. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турында карар, кабул ителгән көненнән алып ун көн эчендә, «Интернет» челтәрендәге сайтларда урнаштырылырга тиеш.»;

е) 4 өлештә «рәсми матбугат басмасында бастырып чыгарылырга,» сүзләрен төшереп калдырырга, «утыз» сүзен «ун» сүзенә алмаштырырга;

7) 10 статьяның исемендә һәм 1 өлешендә «ачык» сүзен төшереп калдырырга;

8) 11 статьяның беренче һәм җиденче абзацларында «ачык» сүзен төшереп калдырырга;

9) 13 статьяның 2 өлешендә «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законның 32 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән срок чыккан мизгелдән» сүзләрен «бәясен игълан итмичә дәүләт мөлкәтен сатуга йомгак ясаган көннән алып» сүзләренә алмаштырырга;

10) 16 статьяда:
а) 3 өлештә «басылып чыгарга тиеш» сүзләрен «булырга тиеш» сүзләренә алмаштырырга;
б) 4 өлештә «бастырып чыгарылган» сүзләрен «Интернет» челтәрендәге сайтларда урнаштырылган» сүзләренә алмаштырырга;

11) 19 статьяда:
а) исемдә, 1 — 3 өлешләрдә «ачык» сүзен төшереп калдырырга;
б) 4 өлештә «ачык» сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

«Хуҗалык җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең идарә һәм контроль органнарында дәүләт вәкилләренең катнашу тәртибе турында» 2000 елның 19 октябрендәге 383 номерлы Татарстан Республикасы Законының преамбуласында, 1 статьясында, 2 статьясындагы беренче өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 11 (9); 2005, № 12 (I өлеш) «ачык» сүзен төшереп калдырырга.

**3 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» 2007 елның 26 июлендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 3 өлешенең 2 пунктында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш) «ачык» сүзен төшереп калдырырга.



**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 7 октябре
№ 70-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1017. Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Зеленодольск шәһәре», «Васильево шәһәр тибындагы поселогы», «Әйшә авыл җирлеге» һәм «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**

«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 12 (VII өлеш); 2010, № 12 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 7; 2014, 12 (VII өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре
**карта-схемасы**






«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Зеленодольск шәһәре |
| 2 | Васильево шәһәр тибындагы поселогы |
| 3 | Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы |
| 4 | Әйшә авыл җирлеге |
| 5 | Акъегет авыл җирлеге |
| 6 | Бишнә авыл җирлеге |
| 7 | Олы Ачасыр авыл җирлеге |
| 8 | Большие Ключи авыл җирлеге |
| 9 | Олы Карагуҗа авыл җирлеге |
| 10 | Олы Шырдан авыл җирлеге |
| 11 | Олы Җәке авыл җирлеге |
| 12 | Күгәй авыл җирлеге |
| 13 | Күгеш авыл җирлеге |
| 14 | Мамадыш-Әкил авыл җирлеге |
| 15 | Мулла Иле авыл җирлеге |
| 16 | Түбән Урысбага авыл җирлеге |
| 17 | Новопольский авыл җирлеге |
| 18 | Норлат авыл җирлеге |
| 19 | Октябрь авыл җирлеге |
| 20 | Осиново авыл җирлеге |
| 21 | Раифа авыл җирлеге |
| 22 | Рус Әҗиле авыл җирлеге |
| 23 | Свияжск (Зөя) авыл җирлеге |
| 24 | Өтәшкә авыл җирлеге |

»;

2) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге «Васильево шәһәр тибындагы поселогы», «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре, Әйшә, Октябрь, Свияжск (Зөя) авыл җирлекләре, Югары Ослан муниципаль районы һәм Марий Эл Республикасы белән чиктәш.

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Марий Эл Республикасы белән чиктәш җирдә «Зеленодольск шәһәре», «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Улитино авылыннан 1,6 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 53 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Әйшә авыл җирлеге һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Улитино авылыннан 2,3 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 54 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Свияжск (Зөя) авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Свияжск (Зөя) авыл җирлеге һәм «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогыннан 3,2 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 479365,96, Y = 1271527,30 координаталы 23 нче тоташу ноктасыннан алып



көньяк-көнчыгышка таба 6,1 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Свияжск (Зөя) авыл җирлеге һәм Югары Ослан муниципаль районы чикләре тоташкан урында Васильево шәһәр тибындагы поселогыннан 2,6 км көньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Югары Ослан муниципаль районы белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып Зеленодольск муниципаль районы чиге буйлап «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Октябрь авыл җирлеге һәм Югары Ослан муниципаль районы чикләре тоташкан урында Васильево шәһәр тибындагы поселогыннан 2,1 км көньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Октябрь авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Зеленодольск шәһәре», «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре һәм Октябрь авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Октябрь поселогыннан 1,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан X = 479490,14, Y = 1282861,03 координаталы 22 нче тоташу ноктасыннан алып 100 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап уза, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м Куйбышев сусаклагычы култыгына кадәр, шуннан соң, Куйбышев сусаклагычы култыгын кисеп үтеп, 100 м бара, аннары яр буе линиясеннән 2 м ераклыкта Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 400 м уза, шуннан соң, Куйбышев сусаклагычы култыгын кисеп үтеп, 50 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, яр буе линиясеннән 2 м ераклыкта Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 1,1 км уза, шуннан соң Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча каршы як ярга кадәр 150 м, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы култыгы яры буенча 1,6 км бара, аннары «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Васильево участок урманчылыгындагы 68 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 10 м бара, шуннан соң, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка агач-куак үсемлекләре массивы буйлап 250 м уза, аннары 66 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 650 м бара, шуннан соң 61 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 350 м бара, аннары Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м бара, аннары

62 нче урман кварталы буйлап төньяк-көнбатышка таба 150 м уза, алга таба 62 нче урман кварталының көнбатыш, төньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап төньякка таба 1,2 км, көнчыгышка таба 850 м, көньякка таба 300 м, көньяк-көнбатышка таба 100 м бара, аннары 159, 160, 161 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 1,4 км уза, шуннан соң 152 нче урман кварталының көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап көнчыгышка таба 550 м һәм төньякка таба 550 м бара, аннары 153 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап һәм 154 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап көнчыгышка таба 550 м һәм төньякка таба 150 м бара, шуннан соң, 154, 155, 156 нчы урман кварталларын кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,5 км уза, 156 нчы урман кварталы буйлап төньякка таба 100 м бара, шуннан соң Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чигеннән 150 м ераклыкта авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 600 м һәм, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 500 м М-7 Идел автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чигенә кадәр уза, шуннан соң М-7 Идел автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буенча 1,4 км бара, аннары урман массивы чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 600 м уза, шуннан соң 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 200 м бара, шуннан соң урман массивының көнчыгыш чиге буйлап көньякка таба 20 м уза, аннары, сынык сызык ясап, 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 2,9 км уза, шуннан соң 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 50 м бара, аннары 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 250 м 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 250 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап уза, шуннан соң 149 нчы, 154 нче урман кварталлары буйлап 350 м көньяк-көнбатышка таба, 50 м көнчыгышка таба бара, шуннан соң 149 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 200 м көньякка таба уза, аннары 148 нче, 149 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап 850 м көнбатышка таба бара, шуннан соң 152 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м көнбатышка таба уза, аннары 100 м 148 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, аннары 151 нче урман кварталының көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап 550 м көньякка таба, 550 м көнбатышка таба уза, шуннан соң 150 нче урман кварталының көньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап 800 м көнбатышка таба һәм 100 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 57 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 300 м



төньякка таба уза, шуннан соң 56 нчы урман кварталы буйлап 850 м көнбатышка таба бара, аннары 61 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 1,2 км көньякка таба уза, шуннан соң Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба уза, сынык сызык ясап, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, 61 нче урман кварталы буйлап 350 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң 66 нчы урман кварталы буйлап 650 м көньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м агач-куак үсемлекләре массивы буенча уза, аннары яр буе линиясеннән 2 м ераклыкта Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң, Куйбышев сусаклагычы култыгын кисеп үтеп, 100 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, Куйбышев сусаклагычы яры буенча 1,1 км көньяк-көнбатышка таба бара, аннары, Куйбышев сусаклагычы култыгын кисеп үтеп, 100 м уза, аннары күмәк бакчаларның көньяк чиге буйлап 350 м бара, шуннан соң Куйбышев сусаклагычының яр буе линиясе буенча 400 м көнбатышка таба уза, шуннан соң Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 100 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 300 м бара, шуннан соң урман массивының көньяк чиге буенча 40 м уза, аннары күмәк бакчаларның көньяк чиге буйлап 100 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, аннары агач-куак үсемлекләре массивы буенча 100 м бара, шуннан соң күмәк бакчаларның көньяк чиге буенча 550 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Куйбышев сусаклагычы ярына кадәр 100 м көньякка таба бара, шуннан соң, утрауны кисеп үтеп, 1,0 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 550 м Куйбышев сусаклагычы яры буенча, шуннан соң, утрауны кисеп үтеп, Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 950 м көньякка таба, 5,0 км көньяк-көнбатышка таба, 3,0 км төньяк-көнбатышка таба «Васильево шәһәр тибындагы поселогы», «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлекләре һәм Әйшә авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Васильево шәһәр тибындагы поселогыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 478416,66, Y = 1274733,55 координаталы 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Әйшә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 3,4 км төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң, утрауларны кисеп үтеп, 2,1 км төньякка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап аның сул ярына кадәр уза, аннары көнчыгышка таба 20 м шушы яр буйлап бара, шуннан соң, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,2 км төньякка таба, сынык сызык ясап, «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әйшә участок урманчылыгындагы 74 нче урман кварталының һәм 71 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 500 м сәнәгать объектының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 71 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м көньяк-көнбатышка таба, көнбатыш чиге буйлап 300 м төньякка таба, төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,0 км төньяк-көнчыгышка таба уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 150 м 71 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 350 м 72 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м 70 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньякка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 200 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 400 м 70 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, урман массивын кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көнбатышка таба, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м урман массивы буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 100 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 2,3 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң, шушы урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м, агач-куак үсемлекләре массивын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 1,2 км урман полосасына кадәр бара, көнчыгышка таба 550 м урман полосасының көньяк чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 400 м, урман массивын һәм профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп,



төньяк-көнчыгышка таба 200 м бара, 1,8 км профильле башка автомобиль юлы буйлап уза, сынык сызык ясап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 150 м урман массивы буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 250 м 43 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м 47 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м сазлык буйлап, 1,0 км 47 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 1,7 км 47 нче, 46 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көнбатышка таба 650 м «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зеленодольск участок урманчылыгындагы 31 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м аның буенча бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 1,1 км 39 нчы, 47 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап уза, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м аның буенча бара, аннары, тимер юл тармагына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньякка таба 1,6 км 47 нче, 56 нчы урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап уза, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м аның буенча бара, 1,1 км 56 нчы, 72 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, профильле автомобиль юлына һәм Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, 103 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары көньякка таба 1,1 км шушы тимер юлга бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, аның буйлап 50 м көнбатышка таба уза, аннары шушы тимер юлга бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап 150 м төньякка таба уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 350 м 103 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 103 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көнбатышка таба 150 м 103 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 500 м 103 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 103 нче, 102 нче урман кварталларының

көньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 750 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң көнбатышка таба 750 м 102 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 1,0 км 101 нче урман кварталының көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап уза, шуннан соң көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньякка таба 400 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 100 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 500 м көнбатышка таба бара, аннары көньякка таба, сынык сызык ясап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 117 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 350 м көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 200 м көньякка таба бара, аннары көнбатышка таба 1,2 км 117 нче, 116 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 125 нче, 127 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 1,5 км көньяк-көнбатышка таба бара, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 127 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м көньякка таба һәм көньяк чиге буйлап 100 м көнбатышка таба бара, шуннан соң көньякка таба, сынык сызык ясап, 1,1 км 135 нче, 144 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көнбатышка таба 350 м 144 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, 950 м сәнәгать объектының төньяк чиге буйлап һәм көньяк-көнбатышка таба 350 м төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 1,0 км сәнәгать объектының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 148 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м көньяк-көнбатышка таба һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сәнәгать объектының көнбатыш чиге буйлап 150 м көньякка таба, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатыш чиге буйлап 900 м көньяк-көнчыгышка таба бара, 250 м Зеленодольск шәһәрен һәм Марий Эл Республикасының Волжск шәһәрен тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап бара, аннары төньякка таба, сынык сызык ясап, 300 м, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 152 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көнчыгышка таба 250 м әлеге тимер юлга бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап бара, аннары төньякка таба 150 м 152 нче урман кварталының төньяк-



көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 750 м, Зеленодольск шәһәрен һәм Марий Эл Республикасының Волжск шәһәрен тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, урман массивының көнчыгыш чиге буйлап 100 м көньякка таба, 300 м 153 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 150 м авыл хуҗалыгында файдаланылмый торган җирләр буйлап Куйбышев сусаклагычының сул ярына кадәр бара, 350 м Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 54 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 7,4 км көнбатышка таба, 350 м төньякка таба 53 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

3) 4 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Әйшә, Новопольский һәм Октябрь авыл җирлекләре белән чиктәш.»;

б) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Зеленодольск шәһәре», «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре һәм Октябрь авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Октябрь поселогыннан 1,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан X = 479490,14, Y = 1282861,03 координаталы 22 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 550 м Куйбышев сусаклагычы яры буйлап, шуннан соң Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап, утрауны кисеп үтеп, 950 м көньякка таба, аннары 5,0 км көньяк-көнбатышка таба, 3,0 км төньяк-көнбатышка таба «Васильево шәһәр тибындагы поселогы», «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлекләре һәм Әйшә авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Васильево шәһәр тибындагы поселогыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X= 478416,66, Y= 1274733,55 координаталы 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

в) дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) җиденче абзацта «12 нче тоташу ноктасыннан алып төньякка таба 1,2 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буй-

лап аның сул ярына кадәр бара, шуннан соң көнчыгышка таба 750 м шушы яр буйлап уза» сүзләрен «22 нче тоташу ноктасыннан алып 200 м көнчыгышка таба күмәк бакчаларның көньяк чиге буйлап уза» сүзләренә алмаштырырга;

4) 6 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта «, Свияжск (Зөя)» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) сигезенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

в) тугызынчы абзацта «23 нче тоташу ноктасыннан алып» сүзләрен «18 нче тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 3,4 км төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң» сүзләренә алмаштырырга;

5) 23 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге» сүзләрен «Зеленодольск шәһәре», «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре» сүзләренә алмаштырырга;

б) бишенче абзацта «12 нче тоташу ноктасыннан алып төньякка таба 1,2 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап аның сул ярына кадәр бара, шуннан соң көнчыгышка таба 750 м шушы яр буйлап уза» сүзләрен «Зеленодольск шәһәре», «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре һәм Октябрь авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Октябрь поселогыннан 1,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан X = 479490,14, Y = 1282861,03 координаталы 22 нче тоташу ноктасыннан алып 200 м көнчыгышка таба күмәк бакчаларның көньяк чиге буйлап уза» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Октябрь авыл җирлеге чиге «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып 100 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап уза, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Куйбышев сусаклагычы култыгына кадәр 500 м, шуннан соң, Куйбышев сусаклагычы култыгын кисеп үтеп, 100 м бара, аннары Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап яр буе линиясеннән 2 м ераклыкта 400 м уза, шуннан соң, Куйбышев сусаклагычы култыгын кисеп үтеп, 50 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап яр линиясеннән 2 м ераклыкта 1,1 км уза, шуннан соң Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча каршы як ярына кадәр 150 м, шуннан соң 1,6 км төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, Куйбышев сусаклагычы култыгы яры буйлап



бара, аннары «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Васильево участок урманчылыгындагы 68 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 10 м төньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, агач-куак үсемлекләре массивы буйлап 250 м уза, аннары 66 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 650 м бара, шуннан соң 350 м көньяк-көнчыгышка таба 61 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м уза, шуннан соң, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 250 м бара, аннары 150 м төньяк-көнбатышка таба 62 нче урман кварталы буйлап уза, шуннан соң 62 нче урман кварталының көнбатыш, төньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап 1,2 км төньякка таба, 850 м көнчыгышка таба, 300 м көньякка таба, 100 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары 159, 160, 161 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап 1,4 км көнчыгышка таба уза, шуннан соң 152 нче урман кварталының көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап 550 м көнчыгышка таба һәм 550 м төньякка таба бара, аннары 153 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап һәм 154 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 550 м көнчыгышка таба һәм 150 м төньякка таба бара, шуннан соң, 154, 155, 156 нчы урман кварталларын кисеп үтеп, 1,5 км көньяк-көнчыгышка таба уза, 100 м төньякка таба 156 нчы урман кварталы буйлап бара, шуннан соң Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чигеннән 150 м ераклыкта авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м төньякка таба һәм, сынык сызык ясап, 500 м төньяк-көнбатышка таба М-7 Идел автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чигенә кадәр уза, шуннан соң М-7 Идел автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буенча 1,4 км бара, аннары 600 м көньяк-көнчыгышка таба урман массивы чиге буйлап уза, шуннан соң 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 200 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң 20 м көньякка таба урман массивының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,9 км көньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, шуннан соң 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м бара, аннары агач-куак үсемлекләре массивы буйлап 250 м уза, шуннан соң 149 нчы, 154 нче урман квартал-

лары буйлап 350 м көньяк-көнбатышка таба, 50 м көнчыгышка таба бара, шуннан соң 149 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 200 м көньякка таба уза, аннары 148 нче, 149 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап 850 м көнбатышка таба бара, шуннан соң 152 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м көнбатышка таба уза, аннары 148 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 100 м бара, аннары 151 нче урман кварталының көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап 550 м көньякка таба, 550 м көнбатышка таба уза, шуннан соң 150 нче урман кварталының көньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап 800 м көнбатышка таба һәм 100 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 57 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 300 м төньякка таба уза, шуннан соң 56 нчы урман кварталы буйлап 850 м көнбатышка таба бара, аннары 61 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 1,2 км көньякка таба уза, шуннан соң Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба бара, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 400 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары 61 нче урман кварталы буйлап, сынык сызык ясап, 350 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң 66 нчы урман кварталы буйлап 650 м көньяк-көнчыгышка таба, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап уза, аннары Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап яр буе линиясеннән 2 м ераклыкта, сынык сызык ясап, 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң, Куйбышев сусаклагычы култыгын кисеп үтеп, 100 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң Куйбышев сусаклагычы яры буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км көньяк-көнбатышка таба бара, аннары, Куйбышев сусаклагычы култыгын кисеп үтеп, 100 м уза, аннары күмәк бакчаларның көньяк чиге буйлап 350 м бара, шуннан соң Куйбышев сусаклагычының яр буе линиясе буйлап 400 м көнбатышка таба уза, шуннан соң Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 100 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 300 м бара, шуннан соң урман массивының көньяк чиге буенча 40 м уза, аннары күмәк бакчаларның көньяк чиге буйлап 100 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, аннары агач-куак үсемлекләре массивы буенча 100 м бара, шуннан соң күмәк бакчаларның көньяк чиге буйлап 550 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Куйбышев сусаклагычы ярына кадәр 100 м көньякка таба бара, шуннан соң Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 1,0 км, утрауны кисеп үтеп, 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;



6) 27 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Свияжск (Зөя) авыл җирлеге «Зеленодольск шәһәре», «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре һәм Югары Ослан муниципаль районы белән чиктәш.»;

б) өченче абзацта «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм» сүзләрен «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге» сүзләренә алмаштырырга;

в) дүртенче абзацта «, Әйшә һәм Свияжск (Зөя) авыл җирлекләре» сүзләрен «һәм Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» сүзләренә алмаштырырга;

г) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Свияжск (Зөя) авыл җирлеге чиге «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 6,12 км көньяк-көнчыгышка таба 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

д) алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 7 октябре
№ 71-ТРЗ

Муниципаль берәмлекләрнең үзгәрешләр исәпкә алынган чикләре **карта-схемасы**

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта








**1018.«Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» 2009 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), «, сыра һәм аның нигезендә әзерләнә торган эчемлекләр» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә «, сыра һәм аның нигезендә әзерләнә торган эчемлекләрне» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2 өлешнең 6 пунктында «, сыра һәм аның нигезендә әзерләнә торган эчемлекләрне» сүзләрен төшереп калдырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 8 октябре
№ 72-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1019. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле $4^2$ пункт өстәргә:

«$4^2$) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы буйсынуындагы медицина оешмаларында кеше органнарын һәм тукымаларын трансплантацияләүгә (күчереп утыртуга), шул исәптән трансплантацияләү (күчереп утырту) максатларында органнарның һәм тукымаларның донорлыгына бәйле медицина эшчәнлеген оештыру;»;

2) 25 статьяга түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:

«$6^1$) трансплантацияләү (күчереп утырту) максатларында органнарның һәм тукымаларның донорлыгына бәйле һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы буйсынуындагы медицина оешмаларына бүлеп бирү өчен каралган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән гамәлгә ашырыла торган медицина эшчәнлеге буенча;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 8 октябре
№ 73-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1020. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 3, № 9; 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяга:

а) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасы идарә органнары – халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өчен җәлеп ителә торган көчләрнең эшчәнлеген координацияләү өчен төзелә торган органнар.»;

б) түбәндәге эчтәлекле икенче өлеш өстәргә:

«Әлеге Законда кулланыла торган башка терминнар һәм төшенчәләр «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – Федераль закон) билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.»;

2) 8[1] статьяның өченче абзацында «федераль» сүзен «Федераль» сүзенә алмаштырырга;

3) 10 статьяның унҗиденче абзацында «федераль» сүзен «Федераль» сүзенә алмаштырырга;

4) 16 статьяның беренче өлешендә «федераль» сүзен «Федераль» сүзенә алмаштырырга;

5) 19 статьяда:

а) беренче өлешнең беренче абзацында «федераль» сүзен «Федераль» сүзенә алмаштырырга;

б) икенче өлештә «федераль» сүзен «Федераль» сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 8 октябре
№ 74-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1021. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында вөждан иреге һәм дин тоту иреге, шул исәптән теләсә кайсы динне индивидуаль яисә башкалар белән бергә тоту яисә берсен дә тотмау, гыйбадәт кылулар, башка дини йолалар һәм тантаналар үткәрү, дингә өйрәтү һәм дини тәрбия бирү, дини һәм башка инануларны ирекле сайлау һәм үзгәртү, дин тоту һәм тарату, шул исәптән дини берләшмәләр төзеп, шулар нигезендә эш итү хокукы гарантияләнә.»;

2) 6 статьяда түбәндәге эчтәлекле 3[1] пункт өстәргә:

«3[1]. Дини берләшмәләр Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дини берләшмәләрнең эчке таләпләре белән билгеләнә торган рәвешләрдә үзенең тарафдарларын дингә өйрәтергә һәм аларга дини тәрбия бирергә хокуклы. Дингә өйрәтү һәм дини тәрбия бирү белем бирү эшчәнлеге булып тормый.»;

3) 9 статьяда:

а) 1 пунктта түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: «Дини төркемгә Россия Федерациясе гражданнары керә, шулай ук Россия Федерациясе территориясендә даими һәм законлы нигезләрдә яшәүче башка затлар керергә мөмкин.»;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дини төркемнең эшли башлавы турында «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә дини оешманы дәүләт теркәвенә алу хакындагы карарны кабул итәргә вәкаләтле органга хәбәр ителергә тиеш.

Дини төркем дини оешманы дәүләт теркәвенә алу хакындагы карарны кабул итәргә вәкаләтле органга иң соңыннан хәбәр ителгән көннән алып кимендә өч елга бер мәртәбә үз эшчәнлеген дәвам итү турында хәбәрнамә бирә.»;

4) 11 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Унсигез яшенә җиткән һәм бер урында йә бер шәһәр яисә авыл җирлегендә даими яшәүче кимендә ун Россия Федерациясе гражданы җирле дини оешманың гамәлгә куючылары була алалар.»;

5) 30 статьяның 4 пунктында:

а) икенче һәм өченче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бер үк диндәге үзәкләштерелгән дини оешма структурасына керми торган җирле дини оешмалар дәүләт теркәвенә алу көненнән алып (төзелгәндә) ун ел дәвамында әлеге Законның 6 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларында (балигъ булган гражданнарга карата өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларын төзү хокукыннан тыш), 19 статьясындагы 4 пунктында, 22 статьясындагы 2 пунктында (массакүләм мәгълүмат чараларына карата), «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 5 пунктында һәм 20 статьясындагы 2 пунктында каралган хокуклардан файдаланмыйлар, шулай ук үзәкләштерелгән дини оешманың гамәлгә куючылары булырга хокуксыз булалар.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 8 октябре
№ 75-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1022. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 21 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешманы гамәлгә куючы баланы карап торган һәм караган өчен ата-анадан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүне (алга таба – ата-ана түләве) һәм, әлеге Законда башкасы билгеләнмәгән булса, аның күләмен билгели. Гамәлгә куючы үзе билгеләгән очракларда һәм тәртиптә ата-ана түләвенең күләмен киметергә яисә ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) аерым категорияләреннән аны түләттермәскә хокуклы. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмада баланы карап торган һәм караган өчен гамәлгә куючы түләсә, ата-ана түләве билгеләнми.»;

2) 4 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында баланы карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең күләме, баланы карап тору һәм карау шартларына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасының һәр муниципаль берәмлеге өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән максималь күләмнән артыграк була алмый.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 8 октябре
№ 76-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1023. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» 2007 елның 26 июлендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (II өлеш); 2011, № 10 (II өлеш), 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Дәүләт мөлкәте өчен аренда түләве күләмен билгеләү тәртибе, шулай ук аренда түләве буенча ташламалар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 9 октябре
№ 77-ТРЗ



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1024. Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 74 статьяның 3 өлешендә «Россия Федерациясе Саклык банкы бүлегендә бала исеменә ачылган счетка» сүзләрен «, күрсәтелгән акчалар, аларның суммасына капиталлаштырылган (исәпләнгән) процентларны да кертеп, Россия Федерациясе банкларында физик затлар кертемнәренең мәҗбүри иминият системасында иминләштерелгән һәм бер банк счетындагы яисә счетларындагы акчаларның җыелма күләме «Россия Федерациясе банкларында физик затларның кертемнәрен иминләштерү турында» 2003 елның 23 декабрендәге 177-ФЗ номерлы Федераль законда кертемнәр буенча каралган каплау күләменнән артмаса, банкта яисә банкларда бала исеменә ачылган счетка яисә счетларга» сүзләренә алмаштырырга;

2) 116 статьяның 1 өлешендә:
а) 9 пунктта «иҗтимагый иминлеккә» сүзләреннән соң «, тынычлыкка һәм кешелек иминлегенә» сүзләрен өстәргә;
б) 10 пунктта «иҗтимагый иминлеккә» сүзләреннән соң «, тынычлыкка һәм кешелек иминлегенә» сүзләрен өстәргә;

3) 134 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында «иҗтимагый иминлеккә» сүзләреннән соң «, тынычлыкка һәм кешелек иминлегенә» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 9 октябре
№ 78-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1025. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 — 12; 1994, № 1 — 2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 2, № 11; 1999, № 3; 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның өченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хосусый янгыннан саклануның саны һәм техник тәэмин ителеше нормативлары аның милекчесе тарафыннан, янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документлар таләпләрен исәпкә алып, ирекле нигездә билгеләнә.»;

2) 19 статьяда:

а) икенче өлештә «мөлкәтне коткару һәм (яисә)» сүзләреннән соң «шартлау куркынычы булган предметлар,» сүзләрен өстәргә;



б) өченче өлештә «янгыннан саклану гарнизоннары» сүзләрен «янгыннан коткару гарнизоннары» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 9 октябре
№ 79-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1026. «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 10 (I өлеш); 2007, № 10; 2008, № 11 (III өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешендә «(алга таба — оешмалар)» сүзләреннән соң «, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре иҗтимагый советларының (алга таба — муниципаль берәмлекләр иҗтимагый советлары)» сүзләрен өстәргә;

2) 4 статьяда:

а) 1 пунктта «оешмаларның» сүзеннән соң «, муниципаль берәмлекләр иҗтимагый советларының» сүзләрен өстәргә;

б) 2 пунктта «оешмаларның» сүзеннән соң «, муниципаль берәмлекләр иҗтимагый советларының» сүзләрен өстәргә;

3) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. **Иҗтимагый палата составы**

1. Иҗтимагый палата 70 кеше составында төзелә.

2. Иҗтимагый палатаның яңа составы тиешенчә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан 20 кеше, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 20 кеше һәм гамәлдәге составтагы Иҗтимагый палата тарафыннан 30 кеше исәбеннән раслана.

3. Иҗтимагый палатаның яңа раслана торган составына кадәрге Иҗтимагый палатаның рәттән ике составында Иҗтимагый палата әгъзалары булган затлар яңа составтагы Иҗтимагый палата әгъзалары була алмыйлар.»;

4) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 статья. **Иҗтимагый палата әгъзалары урыннарына кандидатлар күрсәтү тәртибе**

1. Иҗтимагый палата әгъзалары урыннарына кандидатлар күрсәтү хокукына Татарстан Республикасының бөтен территориясендә, шулай ук аерым районнар һәм шәһәрләр территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар, шул исәптән бөтенроссия һәм төбәкара оешмаларның гамәлдәге составтагы Иҗтимагый палата вәкаләтләре тәмамланган көнгә кадәр кимендә бер ел кала законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән территориаль бүлекчәләре, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең иҗтимагый советлары ия була.

2. Иҗтимагый палатага үз вәкилен күрсәтергә теләк белдергән оешма Иҗтимагый палатаның яңа составы төзелү турында мәгълүмати хәбәр массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көннән алып бер ай эчендә тиешенчә Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына яисә гамәлдәге составтагы Иҗтимагый палатага оешманың җитәкче коллегиаль органы карары белән рәсмиләштерелгән Иҗтимагый палата составына үз вәкилен кертү турында гариза җибәрә. Гаризага оешманы дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның күчермәсе, оешма уставы нигезендә вәкаләтле булган органның Иҗтимагый палата әгъзасы урынына кандидат күрсәтү турында карары, кандидат турында белешмәләр һәм кандидатның Иҗтимагый палата эшендә катнашуга язма ризалыгы, оешма эшчәнлеге турында мәгълүмат теркәп бирелә.



3. Иҗтимагый палатага үз вәкилен күрсәтергә теләк белдергән муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советы Иҗтимагый палатаның яңа составы төзелү турында мәгълүмати хәбәр массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көннән алып бер ай эчендә гамәлдәге составтагы Иҗтимагый палатага муниципаль берәмлек иҗтимагый советының карары белән рәсмиләштерелгән Иҗтимагый палата составына үз вәкилен кертү турында гариза җибәрә. Гаризага муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советын төзү турындагы норматив хокукый актның күчермәсе, муниципаль берәмлек иҗтимагый советының Иҗтимагый палата әгъзасы урынына кандидат күрсәтү турында карары, кандидат турында белешмәләр һәм кандидатның Иҗтимагый палата эшендә катнашуга язма ризалыгы теркәп бирелә.

4. Иҗтимагый палатаның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган әгъзасы урынына Иҗтимагый палата составына вәкил күрсәткәндә, Иҗтимагый палатага үз вәкилен күрсәтергә теләк белдергән оешма үз вәкилен Иҗтимагый палата составына кертү турындагы гаризасын Иҗтимагый палата әгъзалары урыннарына кандидатлар күрсәтү турында мәгълүмати хәбәр массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көннән алып бер ай эчендә Иҗтимагый палатаның вәкаләтләре туктатылган әгъзасын раслаган органга җибәрә. Иҗтимагый палатаның элекке составтагы Иҗтимагый палата тарафыннан расланган әгъзасының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советы шулай ук үз вәкилен кертү турында гариза җибәрергә хокуклы.

5. Иҗтимагый палатаның яңа составын төзи башлау турында мәгълүмати хәбәр Иҗтимагый палата Советы тарафыннан гамәлдәге составтагы Иҗтимагый палатаның вәкаләтләр чоры тәмамланырга кимендә өч ай кала рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла.»;

5) 7 статьяның 1 өлешендә «оешмалар» сүзеннән соң «, муниципаль берәмлекләрнең иҗтимагый советлары» сүзләрен өстәргә;

6) 9 статьяның 1 өлешендә «өч ел» сүзләрен «дүрт ел» сүзләренә алмаштырырга;

7) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ статья өстәргә:

«$9^1$ статья. **Иҗтимагый палата составын яңарту**

1. Иҗтимагый палатаның гамәлдәге составы, вәкаләтләренең беренче ике елы узганнан соң, Иҗтимагый палата карары нигезендә яңартылырга мөмкин.

2. Әлеге статья максатларында Иҗтимагый палата составын яңарту дигәндә аның кайбер әгъзалары вәкаләтләренең вакытыннан алдан туктатылуы аңлашыла. Иҗтимагый палатаның составы яңартылуга бәйле рәвештә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла торган әгъзаларының саны Иҗтимагый палата тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә. Шул ук вакытта Иҗтимагый палата әгъзаларының Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, элекке составтагы Иҗтимагый палата тарафыннан расланган исемлекләренең һәркайсы иң күбе дүрттән бер өлешкә үзгәртелә ала.

3. Иҗтимагый палата составын яңарту турында карарны Иҗтимагый палата Советы тәкъдиме буенча, Иҗтимагый палата әгъзаларының эш нәтиҗәлелеген исәпкә алып, Иҗтимагый палата кабул итә. Карарда Иҗтимагый палатаның составы яңартылуга бәйле рәвештә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла торган әгъзалары күрсәтелә.»;

8) 13 статьяда:

а) 1 өлештә:

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$) Иҗтимагый палата әгъзасына кагылышлы әлеге Законның $9^1$ статьясы нигезендә вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителсә;»;

түбәндәге эчтәлекле $8^1$ пункт өстәргә:

«$8^1$) аның кандидатурасын күрсәткән муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советы тарафыннан чакыртып алынса;»;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Иҗтимагый палата әгъзасының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, аның кандидатурасын күрсәткән оешма йә аның кандидатурасын күрсәткән муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советы җиде көн эчендә шушы оешмадан йә муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советыннан Иҗтимагый палата әгъзасын раслаган органга яңа кандидатура буенча тәкъдим кертә ала, моңа әлеге статьяның 1 өлешендәге $1^1$, 2, 7, 8 һәм $8^1$ пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча вәкаләтләр туктатылу очраклары керми.»;



в) 5 өлештә «оешма» сүзеннән соң «, муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советы» сүзләрен өстәргә;

9) 14 статьяда «Оешма» сүзеннән соң «, муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советы» сүзләрен, «оешма» сүзеннән соң «, муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советы» сүзләрен өстәргә;

10) 15 статьяның 2 өлешендә:

а) «оешмаларның» сүзеннән соң «, муниципаль берәмлекләр иҗтимагый советларының» сүзләрен өстәргә;

б) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) Иҗтимагый палатаның Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм аларны үстерү турындагы еллык докладын әзерләү һәм бастырып чыгару тәртибе;»;

в) түбәндәге эчтәлекле $11^3$ пункт өстәргә:

«$11^3$) Иҗтимагый палата әгъзаларының эш нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары һәм тәртибе;»;

11) 16 статьяның 4 өлешендә «кимендә өчтән икесе» сүзләрен «яртысыннан күбрәге» сүзләренә алмаштырырга;

12) 23 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23 статья. **Иҗтимагый палатаның Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм аларны үстерү турындагы еллык доклады**

1. Календарь ел беткәннән соң Иҗтимагый палата Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм аларны үстерү турында еллык доклад әзерли һәм аны рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгара, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Иҗтимагый палата сайтына урнаштыра.

2. Иҗтимагый палатаның еллык доклады Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелә, шулай ук Иҗтимагый палата карары буенча башка дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына җибәрелергә мөмкин.

3. Иҗтимагый палата рәисе еллык доклад белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында чыгыш ясый.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 3 өлеше нигезләмәләренең көче (бу Закон редакциясендә) әлеге Закон үз көченә кергәннән соң Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының беренче ике составы оешканда барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә таралмый.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 9 октябре
№ 80-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1027. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяның 13 пунктында «гомуми файдаланудагы» сүзләрен төшереп калдырырга, «авыр йөк ташый торган транс-



порт чаралары» сүзләрен «авыр йөкле транспорт чаралары» сүзләренә алмаштырырга;

2) 13 статьяда:
а) 8 пунктта «куркыныч, авыр һәм (яисә) эре габаритлы йөкләр ташый торган транспорт чаралары» сүзләрен «авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чаралары» сүзләренә алмаштырырга;
б) 9 пунктта «гомуми файдаланудагы» сүзләрен төшереп калдырырга, «авыр йөк ташый торган транспорт чаралары» сүзләрен «авыр йөкле транспорт чаралары» сүзләренә алмаштырырга;

3) 28 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«28 статья. **Автомобиль юллары буйлап авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәте**

1. Автомобиль юллары буйлап эре габаритлы транспорт чарасы, шулай ук массасы йөк белән яисә йөксез һәм (яисә) күчәренә йөкләнеше транспорт чарасының рөхсәт ителә торган массасыннан һәм (яисә) күчәргә рөхсәт ителә торган йөкләнештән ике проценттан артык булган авыр йөкле транспорт чарасы хәрәкәте Федераль законның 31 статьясында билгеләнгән тәртиптә бирелә торган махсус рөхсәт булганда рөхсәт ителә.
2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән махсус рөхсәт бирү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:
1) вәкаләтле органның үзе йә ул вәкаләт биргән ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан – авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы маршруты, маршруты өлеше региональ әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап, мондый автомобиль юлларының участоклары буйлап, ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлекләр (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә урнашкан җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап узган очракта, күрсәтелгән транспорт чарасы маршруты Татарстан Республикасы чикләрендә узу һәм маршрут, маршрут өлеше федераль әһәмияттәге автомобиль юллары, мондый автомобиль юлларының участоклары буйлап узмау шарты белән;
2) муниципаль районның җирле үзидарә органының үзе йә ул вәкаләт биргән ведомство буйсынуындагы оешма тарафыннан – авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы маршруты, маршруты өлеше муниципаль районның җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап, муниципаль район чикләрендәге ике һәм аннан да күбрәк җирлекләр территорияլә-

рендә урнашкан җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап узган һәм федераль, региональ әһәмияттәге автомобиль юллары, мондый автомобиль юлларының участоклары буйлап узмаган очракта;

3) җирлекнең җирле үзидарә органының үзе йә ул вәкаләт биргән ведомство буйсынуындагы оешма тарафыннан — авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы маршруты, маршруты өлеше җирлекнең җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап узган очракта, күрсәтелгән транспорт чарасы маршруты шушы җирлек чикләрендә узу һәм маршрут, маршрут өлеше муниципаль районның федераль, региональ, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары, мондый автомобиль юлларының участоклары буйлап узмау шарты белән;

4) шәһәр округының җирле үзидарә органының үзе йә ул вәкаләт биргән ведомство буйсынуындагы оешма тарафыннан — авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы маршруты, маршруты өлеше шәһәр округының җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап узган һәм федераль, региональ әһәмияттәге автомобиль юллары, мондый автомобиль юлларының участоклары буйлап узмаган очракта;

5) автомобиль юлы милекчесе тарафыннан — авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы маршруты хосусый автомобиль юлы буйлап узган очракта.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендәге 1 — 4 пунктларында каралган очракларда әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән махсус рөхсәт биргән өчен салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт пошлинасы түләнә.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән махсус рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы орган авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы маршрутын мондый маршрут уза торган автомобиль юллары хуҗалары белән, ә Россия Федерациясе хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән рөхсәт ителгән габаритлар ике проценттан арткан очракта, федераль башкарма хакимиятнең юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге тикшереп тору, күзәтчелек һәм рөхсәт бирү функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органының тиешле бүлекчәләре белән дә килештерә. Авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәте өчен автомобиль юлларының аерым участокларын ныгыту яисә килештерелгән маршрут чикләрендә автомобиль юлларын һәм алар белән кисешә торган корылмаларны, инженерлык коммуникацияләрен төзекләндерү буенча махсус чаралар күрү таләп ителгән очракларда, федераль башкарма хакимиятнең юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге тикшереп тору, күзәтчелек һәм рөхсәт бирү функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органының тиешле бүлекчәләре белән килештерү үткәрелә. Авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чараларының даими маршрутларын билгеләү рөхсәт ителә. Авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы маршрутын килештергән өчен түләү алу рөхсәт ителми.



5. Авыр йөкле транспорт чаралары хуҗалары мондый транспорт чарасы китерәчәк зыянны Федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә каплыйлар.

6. Авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәте өчен автомобиль юлларының техник торышын бәяләү, аларны ныгыту яисә автомобиль юлларын, аларның участокларын, шулай ук автомобиль юлы белән кисешә торган корылмаларны һәм инженерлык коммуникацияләрен төзекләндерү буенча махсус чаралар күрү таләп ителгән очракларда, үз мәнфәгатьләрендә күрсәтелгән транспорт чарасында ташулар гамәлгә ашырыла торган зат, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган махсус рөхсәт алганчы, мондый бәяләүне гамәлгә ашыручы һәм шушы чараларны күрүче юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга әлеге бәяләүне гамәлгә ашыру һәм мондый чараларны күрү чыгымнарын каплый.

7. Авыр йөкле транспорт чарасы күчәренә йөкләнеш транспорт чарасы күчәренә рөхсәт ителә торган йөкләнештән ике процenttан арткан, ләкин 10 процenttан артмаган очракта, мондый транспорт чарасының билгеләнгән даими маршрут буенча хәрәкәтенә махсус рөхсәт, шул исәптән электрон рәвештә дә, гадиләштерелгән тәртиптә бирелә. Күрсәтелгән махсус рөхсәтне гадиләштерелгән тәртиптә бирүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган, хосусый автомобиль юлы милекчесе әлеге махсус рөхсәтне бирү турындагы гариза теркәлгән көннән бер эш көне дәвамында мөрәҗәгать итүчегә авыр йөкле транспорт чарасы китерә торган зыянны каплау хисабына түләү күләмен җиткерәләр.

8. Әлеге статьяның 7 өлешендә күрсәтелгән даими маршрутны билгеләү өчен нигез булып күчәргә рөхсәт ителә торган йөкләнешләрдән 10 процenttан һәм аннан артык булган авыр йөкле транспорт чарасы хәрәкәтенә алдагы 12 ай эчендә бирелгән махсус рөхсәтләр тора.

9. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән вәкаләтле орган һәм җирле үзидарә органнары билгеләгән даими маршрутлар исемлекләре күрсәтелгән органнарның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштырыла.

10. Махсус рөхсәт авыр йөкле транспорт чарасы китерә торган зыянны каплау хисабына түләү кертү расланган көннән бер көннән дә артык булмаган вакытта бирелергә тиеш.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, шушы Законның 1 статьясындагы 3 пунктының ундүртенче — унҗиденче абзацларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пунктының ундүртенче — унҗиденче абзацлары 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 9 октябре
№ 81-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1028. «Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 1998 елның 21 октябрендәге 1818 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 11; 2001, № 1 – 2; 2004, № 2 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 3; 2014, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Китапханәләрдән һәм китапханә хезмәте күрсәтүләрдән инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә тәэмин ителә. Сукырлар, начар күрүчеләр махсус дәүләт китапханәләрендә һәм һәркем файдалана алырлык башка китапханәләрдә китапханә хезмәте күрсәтелүгә һәм документларның нөсхәләрен төрле мәгълүмат туплагычларда үзләренә җайлы махсус форматларда алырга хокуклы.»;



2) 14 статьяның беренче өлешенә түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12) Татарстан Республикасы китапханәләреннән инвалидларның файдалана алуы өчен шартларны.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункт өстәргә:

«$9^1$) Татарстан Республикасы милкендәге мәдәни мирас объектларыннан инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү;»;

2) 5 статьяда:

а) исемендә «Җирлекләрнең һәм шәһәр округларының» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 өлештә:

беренче абзацта «җирлекләр һәм шәһәр округлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «җирлекләр һәм шәһәр округлары» сүзләрен «муниципаль берәмлекләр» сүзләренә алмаштырырга;

в ) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$) җирлекләр яки шәһәр округлары милкендәге мәдәни мирас объектларыннан инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү;».

**3 статья**

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру

турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 4; 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2[1] статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

«6. Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү һәм дәүләт функцияләрен үтәү, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтүләрнең һәм дәүләт функцияләренең федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру функцияләрен һәм дәүләт идарәсен башкаручы органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

2) 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтелә торган инфраструктура объектларыннан инвалидларның (кресло-коляскаларда йөрүче һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп) файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3) 4 статьяда «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре» сүзләрен «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре» сүзләренә алмаштырырга.

**4 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш) түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оештырылу-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмалар спорт объектларыннан инвалидларның (кресло-коляскаларда йөрүче һәм сукырларны



йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп) файдалануы өчен шартлар тудыра.».

**5 статья**

«Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» 2010 елның 14 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш) түбәндәге эчтәлекле 2[1] өлеш өстәргә:

«2[1]. Музейлардан инвалидларның файдалана алуы өчен, музей әйберләре һәм музей коллекцияләре белән танышу мөмкинлеген дә кертеп, шартлар тәэмин итү федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

**6 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оештырылу-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмалар сәламәтлек саклау өлкәсендә инфраструктура объектларыннан инвалидларның (кресло-коляскаларда йөрүче һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп) файдалана алуы өчен шартлар тудыра.».

**7 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 1 – 2) түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларыннан күрү буенча инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

**8 статья**

1. Әлеге Закон 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
2. Әлеге Законның инфраструктура объектларыннан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешенә кагылышлы нигезләмәләре 2016 елның 1 июленнән бары тик яңа гына файдалануга тапшырыла торган яисә реконструкцияләнгән, яңартылган объектларга карата кулланыла.
3. Әлеге Законны гамәлгә ашыру максатларыннан чыгып:
1) инфраструктура объектларыннан инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалану өчен шартлар тәэмин итү максатларыннан чыгып, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары билгеләнгән эшчәнлек өлкәләрендә объектлардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән инвалидларның файдалана алуы күрсәткечләрен яхшырту чараларын раслау һәм гамәлгә ашыру өчен күчеш чоры карала дип билгеләргә;
2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республиксында җирле үзидарә органнары тарафыннан шушы органнарның дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүләре буенча административ регламентларына дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләреннән инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итүгә карата таләпләр әлеге Закон үз көченә кергәннән соң алты ай эчендә кертелә.
4. «Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль законны һәм әлеге Законны үтәүгә бәйле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законда күрсәтелгән максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре хисабына һәм чикләрендә гамәлгә ашырыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 9 октябре
№ 82-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1029. Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

1 статья. **Муниципаль җир контроле**

Муниципаль җир контроле дигәндә җир мөнәсәбәтләре объектларына карата Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы законнарында хокук бозулар өчен административ һәм башка җаваплылык каралган Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары таләпләрен дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның, гражданнарның үтәвен тикшереп тору буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеге аңлашыла.

2 статья. **Дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру**

1. Юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга карата муниципаль җир контроле, Россия Федерациясе Җир кодексында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.
2. Дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына карата муниципаль җир контроле юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3 статья. **Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру**

1. Гражданнарга карата муниципаль җир контроле гражданнар җир мөнәсәбәтләре объектларыннан файдаланганда

ларның Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары таләпләрен үтәвен планлаштырылган һәм планнан тыш тикшерүләр (алга таба – планлаштырылган тикшерү һәм планнан тыш тикшерү) уздырып гамәлгә ашырыла.

2. Планлаштырылган тикшерү иң еш дигәндә өч елга бер тапкыр, планлаштырылган тикшерүләр уздыруның муниципаль җир контроле органы тарафыннан раслана торган еллык планы (алга таба – еллык тикшерүләр планы) нигезендә үткәрелә.

3. Планлаштырылган тикшерүне еллык тикшерүләр планына кертү өчен нигез булып түбәндәгеләрдән соң өч ел узу тора:

1) гражданның җир мөнәсәбәтләре объектына (алга таба – җир кишәрлеге) хокукы барлыкка килгән көннән;

2) җир кишәрлегенә соңгы тапкыр планлаштырылган тикшерү тәгәлләнгән көннән.

4. Расланган еллык тикшерүләр планы кызыксынган затларга аны муниципаль җир контроле органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән йә мөмкин булган башка ысул белән җиткерелә.

5. Планнан тыш тикшерү түбәндәге очракларда үткәрелә:

1) җир законнары таләпләрен бозуның ачыкланган очрагын бетерү хакында элек бирелгән күрсәтмәне граждан тарафыннан үтәү срогы чыкса;

2) муниципаль җир контроле органнарына гражданнардан, шул исәптән индивидуаль эшкуарлардан, юридик затлардан кергән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүмат түбәндәге фактлар хакында булса:

а) гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә зарар салу, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), дәүләтнең иминлегенә зыян китерү куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы барлыкка килү;

б) гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә зарар салу, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), дәүләтнең иминлегенә зыян китерү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу.

6. Әлеге статьяның 5 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, әгәр алар буенча муниципаль җир контроле органына мөрәҗәгать иткән затны билгеләп булмаса,



шулай ук әлеге статьяның 5 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән фактлар турында белешмәләре булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез була алмый.

4 статья. **Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерүләр оештыру тәртибе**

1. Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерүләр муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) тикшерүне билгеләү турында күрсәтмәсе (боерыгы) нигезендә үткәрелә.

2. Муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) тикшерүне билгеләү турында күрсәтмәсендә (боерыгында) түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) муниципаль җир контроле органының исеме;

2) тикшерү үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның, шулай ук тикшерү үткәрү өчен җәлеп ителә торган экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, вазыйфалары;

3) тикшерү үткәрелә торган гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме;

4) тикшерү объекты булган җир кишәрлегенең (алга таба – тикшерелә торган җир кишәрлеге) идентификация билгеләре (җир кишәрлегенең адресы яисә, адресы булмаган очракта, җир кишәрлеге урнашкан урынны башкача тасвирлау, кадастр номеры, җир кишәрлеге керә торган җирләрнең категориясе);

5) тикшерү үткәрүнең хокукый нигезләре;

6) тикшерүнең төре (планлаштырылган яисә планнан тыш) һәм аны үткәрү рәвеше (документлар буенча яисә урынга барып);

7) граждан тапшырырга тиешле документларның исемлеге;

8) тикшерүне үткәрә башлау һәм тәгәлләү датасы.

5 статья. **Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерү үткәрү турында хәбәрнамә**

1. Муниципаль җир контроле органы планлаштырылган тикшерү үткәрү турында гражданга тикшерү үткәрелә башлаганчы кимендә өч эш көне алдан муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) планлаштырылган тикшерүне билгеләү турында күрсәтмәсе (боерыгы) күчермәсен тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы хат белән җибәреп яисә мөмкин булган башка ысул белән хәбәр итә.

2. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш, муниципаль җир контроле органы планнан тыш тикшерү үткәрү турында гражданга тикшерү үткәрелә башлаганчы кимендә 24 сәгать кала мөмкин булган теләсә нинди ысул белән хәбәр итә.

3. Әгәр гражданның җир законнары таләпләрен бозуы аркасында гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зарар салынса, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә) зыян килсә, дәүләтнең иминлегенә куркыныч янаса, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килсә яисә барлыкка килү ихтималы булса, планнан тыш тикшерү үткәрелә башлау турында гражданга алдан хәбәр итү таләп ителми. Бу очракта планнан тыш тикшерү үткәргәндә гражданның яисә аның вәкиленең булмавы тикшерү үткәрү өчен каршылык була алмый.

6 статья. **Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерүләрнең рәвешләре**

1. Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерүләр документлар буенча һәм (яисә) барып тикшерү рәвешләрендә үткәрелә, аларның һәркайсын үткәрү срогы 20 эш көненнән артырга тиеш түгел.

2. Катлаулы һәм (яисә) озак вакытлы тикшеренүләр уздыру, махсус экспертизалар ясау таләп ителүгә бәйле аерым очракларда, тикшерү үткәрә торган затларның дәлилләнгән тәкъдимнәренә нигезләнеп, тикшерү срогы муниципаль җир контроле органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) күрсәтмәсе (боерыгы) белән озайтылырга мөмкин, ләкин 20 эш көненнән дә артыгракка түгел.

3. Документлар буенча тикшерү муниципаль җир контроле органы урнашкан урын буенча үткәрелә. Урынга барып тикшерү тикшерелә торган җир кишәрлегенең факттагы урнашу урыны буенча үткәрелә.

4. Документлар буенча тикшерү предметы гражданның тикшерелә торган җир кишәрлегенә хокукларын һәм бурычларын билгели торган документлардагы белешмәләрдән, шулай ук гражданның җир законнары таләпләрен үтәвенә бәйле документлардан гыйбарәт.

5. Документлар буенча тикшерү барышында иң элек муниципаль җир контроле органы карамагында булган документлар, шул исәптән алдагы тикшерүләр актлары, административ хокук бозулар турында эшләрне карау материаллары һәм гражданга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында элек үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре хакындагы башка документлар карала.



6. Муниципаль җир контроле органы карамагындагы документларда булган белешмәләрнең дөреслеге нигезле шик тудырса йә бу белешмәләр гражданның җир законнары таләпләрен үтәвен бәяләргә мөмкинлек бирмәсә, муниципаль җир контроле органы граждан адресына, документлар буенча тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны һәм аңлатмаларны тапшыруны таләп итеп, дәлилләнгән гарызнамә җибәрә. Дәлилләнгән гарызнамә алынган көннән алып 10 эш көне эчендә граждан муниципаль җир контроле органына гарызнамәдә күрсәтелгән документларны һәм аңлатмаларны тапшырырга тиеш.

7. Муниципаль җир контроле органы гражданнан документлар буенча тикшерү предметына карамый торган белешмәләрне һәм документларны, шулай ук бу орган дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарыннан, башка муниципаль контроль органнарыннан алырга мөмкин белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә тиеш түгел.

8. Документлар буенча тикшергәндә гражданның тикшерелә торган җир кишәрлегенә хокукларын һәм бурычларын билгели торган, муниципаль җир контроле органы карамагында булган документлардагы белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшереп карау йә гражданның җир законнары таләпләрен үтәвен бәяләү мөмкин булмаган очракта, урынга барып тикшерү үткәрелә.

9. Урынга барып тикшерү муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының хезмәт таныклыгын күрсәтүдән, гражданны җитәкченең (җитәкче урынбасарының) урынга барып тикшерүне билгеләү турында күрсәтмәсе (боерыгы) белән һәм урынга барып тикшерүне үткәрүче затларның вәкаләтләре белән, шулай ук урынга барып тикшерүнең максатлары, бурычлары, нигезләре, тикшереп тору чараларының төрләре һәм күләме, экспертлар составы, урынга барып тикшерүгә җәлеп ителә торган эксперт оешмалары вәкилләре, тикшерүне үткәрү сроклары һәм шартлары белән таныштырудан башлана.

10. Граждан муниципаль җир контроле органының урынга барып тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларының һәм урынга барып тикшерүдә катнашучы экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең тикшерелә торган җир кишәрлегенә керә алуын тәэмин итәргә тиеш.

7 статья. **Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе**

1. Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында муниципаль җир контроле органының тикшерү үткәрүче вазыйфаи затлары тарафыннан тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү акты төзелә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) тикшерү актын төзү датасы, вакыты һәм урыны;

2) муниципаль җир контроле органы исеме;

3) муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) тикшерүне билгеләү турында күрсәтмәсенең (боерыгының) датасы һәм номеры;

4) тикшерү үткәргән вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм вазыйфалары;

5) тикшерү үткәрелгән гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме;

6) тикшерү үткәргәндә һәм тикшерү акты төзегәндә шунда булган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

7) тикшерүнең башлану һәм тәмамлану датасы һәм вакыты, тикшерү үткәрү урыны;

8) тикшерү нәтиҗәләре, шул исәптән Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы законнарын бозуларны ачыклау турында белешмәләр;

9) гражданның яисә аның тикшерү вакытында шунда булган вәкиленең тикшерү акты белән танышуы яисә танышудан баш тартуы турында, аларның имзалары булу яисә имза куюдан баш тартулары хакында белешмәләр;

10) тикшерү үткәргән вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның имзалары.

2. Тикшерү акты тикшерү тәмамланганнан соң ук ике нөсхәдә рәсмиләштерелә, аларның берсе кушымталарның (алар булган очракта) күчермәләре белән бергә тикшерү акты белән танышу йә танышудан баш тарту турында расписка белән гражданга яисә аның вәкиленә тапшырыла.

3. Тикшерү үткәргәндә граждан яисә аның вәкиле булмаса, шулай ук алар тикшерү акты белән танышу йә танышудан баш тарту турында расписка бирүдән баш тарткан очракта, тикшерү актының бер нөсхәсе кушымталарның (алар булган очракта) күчермәләре белән бергә, тикшерү тәмамланган мизгелдән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы хат белән гражданга җибәрелә, хатның тапшырылуы турында хәбәр тикшерү актының муниципаль җир контроле органындагы делода саклана торган нөсхәсенә беркетелә.



4. Тикшерү барышында Россия Федерациясе законнарында административ һәм башка җаваплылык каралган җир законнары таләпләрен бозу ачыкланса, муниципаль җир контроле органы тикшерү актының күчермәсен дәүләт җир күзәтчелеге органына җибәрә.

5. Тикшерү барышында Татарстан Республикасы законнарында административ җаваплылык каралган җир законнары таләпләрен бозу ачыкланса, ачыкланган хокук бозу өчен җаваплылыкка тарту күрсәтелгән законнар нигезендә башкарыла.

8 статья. **Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерү үткәргәндә гражданнарның хокуклары**

Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерү үткәргәндә граждан түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерү үткәрелгәндә шунда булырга, тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләргә аңлатмалар бирергә;

2) муниципаль җир контроле органыннан, аның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына кагылышлы мәгълүмат алырга;

3) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актына тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы турында, алар белән, шулай ук муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының кайбер гамәлләре белән килешүе яисә килешмәве хакында мәгълүмат өстәргә;

4) муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының тикшерү барышында гражданның хокукларын бозуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмавына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд тәртибендә шикаять белдерергә.

9 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 13 октябре
№ 83-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1030. 2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты проектын һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын төзү һәм раслау үзенчәлекләре турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 17 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

2016 елның 1 гыйнварына кадәр түбәндәгеләрнең гамәлдә булуын туктатып торырга:

1) план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын (Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын) һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын) төзүгә һәм раслауга, план чорына күрсәтелгән Татарстан Республикасы закон проектлары белән бергә документларны һәм материалларны (Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеш фаразыннан, Татарстан Республикасы бюджет сәясәтенең төп юнәлешләреннән һәм Татарстан Республикасы салым сәясәтенең төп юнәлешләреннән тыш) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертүгә карата Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезләмәләренең (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш);

2) Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $52^1$ статьясындагы 5 һәм 6 пунктларының, 53 статьясындагы 2 пункты 5 пунктчасының, 61 статьясындагы 4 пункты унтугызынчы абзацының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш);



2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш).

**2 статья**

2016 елда түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) Татарстан Республикасы бюджеты (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты) акчаларын алучы тарафыннан бюджет йөкләмәләренең элек бирелгән лимитлары нигезендә 2017 елда түләнергә тиешле йөкләмәләр кабул ителгән шартнамәләр Татарстан Республикасы бюджеты (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты) акчаларын алучыга күрсәтелгән елга бюджет йөкләмәләре лимитлары бирелмәүгә бәйле рәвештә аның инициативасы белән өзелми;

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срокларыннан арткан чорга Татарстан Республикасы бюджет йөкләмәләрен барлыкка китерүгә бәйле шартнамәләр (килешүләр) төзелергә мөмкин.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 17 октябре
№ 84-ТРЗ

## 1031. «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 17 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2014 елның 14 маендагы 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны үткәрү вәкаләтләрен бирү турында»;**

2) преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Закон «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 108-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен тапшырылган 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны үткәрү буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен (алга таба – 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны үткәрү вәкаләтләре) бирә.»;



3) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 статья. **Җирле үзидарә органнарына бирелә торган вәкаләтләр**

Җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен (алга таба шулай ук – авыл хуҗалыгы исәбе) алуга әзерлек һәм аны үткәрү буенча түбәндәге вәкаләтләр бирелә:

1) авыл хуҗалыгы исәбенә алына торган объектлар турында белешмәләр җыючы затларны укыту һәм аларның эшләве өчен, исәп алу кәгазьләрен һәм авыл хуҗалыгы исәбен алуның башка документларын саклау өчен яраклы урыннар белән тәэмин итү;

2) авыл хуҗалыгы исәбенә алына торган объектлар турында белешмәләр җыючы затларны укыту һәм аларның эшләве өчен, исәп алу кәгазьләрен һәм авыл хуҗалыгы исәбен алуның башка документларын саклау өчен яраклы урыннарны тиешенчә саклауны тәэмин итү, шулай ук транспорт чаралары бирү һәм элемтә хезмәтләре күрсәтү.»;

4) 2 статьяда:

а) исемдә «дәүләт вәкаләтләре» сүзләрен «вәкаләтләр» сүзенә алмаштырырга;

б) беренче абзацта «дәүләт вәкаләтләре» сүзләрен «вәкаләтләр» сүзенә алмаштырырга;

5) 3 статьяда:

а) исемдә «дәүләт вәкаләтләре» сүзләрен «вәкаләтләр» сүзенә алмаштырырга;

б) текстта «дәүләт вәкаләтләре» сүзләрен «вәкаләтләр» сүзенә алмаштырырга;

6) 4 статьяда:

а) исемдә «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 өлештә «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

в) 2 өлештә «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

г) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрне исәпләү әлеге Законга кушымтада каралган 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны үткәрү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрне исәпләү методикасы нигезендә башкарыла.»;

д) 4 өлештә «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләр» сүзенә алмаштырырга;

7) 5 статьяда:

а) исемдә «Дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «Вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 өлештә «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

в) 2 өлештә «алуны үткәрүгә әзерлек өчен» сүзләрен «алуга әзерлек һәм аны үткәрү өчен» сүзләренә алмаштырырга;

8) 6 статьяда:

а) исемдә «Дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «Вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 өлештә:

беренче абзацта «Дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «Вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

1 пунктта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

3 пунктта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

4 пунктта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

в) 2 өлештә:

беренче абзацта «Дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «Вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;



1 пунктта «дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеген башкарырга вәкаләтле» сүзләрен «вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җаваплы» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Татарстан Республикасы милкендә булган һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырылган матди чараларның исәбен алуны, алардан нәтиҗәле файдалануны һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән финанс чараларын нәтиҗәле һәм максатчан куллануны тәэмин итәргә;»;

4 пунктны төшереп калдырырга;

5 пунктта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

6 пунктта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

7 пунктта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

9) 7 статьяда:

а) исемдә «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 өлештә «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

в) 2 өлештә:

беренче абзацта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

1 пунктта «дәүләт вәкаләтләренең» сүзләрен «вәкаләтләрнең» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

3 пунктта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

г) 3 өлештә:

беренче абзацта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

1 пунктта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

3 пунктта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

10) 8 статьяда:
а) исемдә «Дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «Вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;
б) текстта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

11) 9 статьяда:
а) исемдә «дәүләт вәкаләтләренең» сүзләрен «вәкаләтләрнең» сүзенә алмаштырырга;
б) беренче абзацта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;
в) 1 пунктта:
беренче абзацта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;
«а» пунктчасында «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;
«б» пунктчасында «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;
г) 2 пунктта:
беренче абзацта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;
«а» пунктчасында «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;
«б» пунктчасында «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;
д) 3 пунктта:
беренче абзацта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;
«а» пунктчасында «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;
«б» пунктчасында «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;

12) 10 статьяда:
а) исемдә «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;
б) 1 өлештә:
беренче абзацта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;
1 пунктта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;
3 пунктта «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;



в) 2 өлештә «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;
г) 3 өлештә «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;
д) 5 өлештә «дәүләт вәкаләтләрен» сүзләрен «вәкаләтләрне» сүзенә алмаштырырга;
13) кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны үткәрү вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны үткәрү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрне исәпләү методикасы

1. Әлеге Методика Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны үткәрү буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарын финанслауны тәэмин итү максатларында эшләнде.
2. Татарстан Республикасы бюджетыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен i-муниципаль районы, шәһәр округы бюджетына бирелә торган субвенция күләме ($P_{общ}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$P_{общ} = Кп \times Нч,$$

монда:
Кп – исәп алуга җәлеп ителә торган персонал саны (исәп алучылар, инструкторлар), кеше;
Нч – бер кешегә исәпләгәндә гомуми тәэминат нормативы, мең сумнарда.

3. Исәп алуга җәлеп ителә торган персонал саны (исәп алучылар, инструкторлар) (Кп) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Кп = Кп_1 + Ки,$$

монда:
$Кп_1$ – җәлеп ителә торган исәп алучылар саны, кеше;
Ки – җәлеп ителә торган инструкторлар саны, кеше.

4. Җәлеп ителә торган исәп алучылар саны ($Кп_1$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Кп_1 = Коб/Нн,$$

монда:
Коб – исәпкә алу объектлары саны, берәмлек;
Нн – бер исәп алучыга йөкләмә нормасы, исәп алу чорына бер исәп алучыга исәпкә алу объектлары саны.

5. Җәлеп ителә торган инструкторлар саны (Ки) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Ки = Кп_1/Нн,$$

монда:
Нн – бер инструкторга йөкләмә нормасы, бер инструкторга җәлеп ителә торган исәп алучылар саны.

6. Бер кешегә исәпләгәндә гомуми тәэминат нормативы (Нч) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Нч = Ач + Оч + Тч + Сч,$$

монда:
Ач – бер кешегә исәпләгәндә исәпкә алу объектлары турында белешмәләр җыючы затларны укыту һәм аларның эшләве өчен, исәп алу кәгазьләрен һәм исәп алуның башка документларын саклау өчен яраклы урынны (алга таба – урын) арендалау нормативы, мең сумнарда;
Оч – бер кешегә исәпләгәндә урынны саклау нормативы, мең сумнарда;
Тч – бер кешегә исәпләгәндә транспорт чараларын бирү нормативы, мең сумнарда;



Сч – бер кешегә исәпләгәндә элемтә буенча хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү нормативы, мең сумнарда.

7. Бер кешегә исәпләгәндә урынны арендалау нормативы (Ач) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Ач = Сб \times П \times Вп,$$

монда:
Сб – урынның 1 квадрат метры өчен аренда түләве күләме (шул исәптән эксплуатация чыгымнары), аена мең сумнарда;
П – бер кешене урнаштыру өчен урын мәйданын билгели торган норматив, квадрат метр;
Вп – бер кешене урнаштыру өчен урын арендалау вакытын билгели торган норматив, ай.

8. Бер кешегә исәпләгәндә урынны саклау нормативы (Оч) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Оч = Сохр \times Вохр,$$

монда:
Сохр – бер кешегә исәпләгәндә урынны саклауны тәэмин итү бәясен билгели торган норматив (урын сак белән тәэмин ителмәгән очракта), аена мең сумнарда;
Вохр – урынны саклау чорын билгели торган норматив, ай.

9. Бер кешегә исәпләгәндә транспорт чараларын бирү нормативы (Тч) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Тч = Стр \times Втр,$$

монда:
Стр – транспорт чарасын биргән өчен бер тәүлеккә түләү күләмен билгели торган норматив, мең сумнарда;
Втр – транспорт чарасын бирү вакытын билгели торган норматив, тәүлек.

10. Бер кешегә исәпләгәндә элемтә буенча хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү нормативы (Сч) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Сч = Сев \times Всв,$$

монда:

Сев — элемтә буенча хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү өчен бер тәүлеккә түләү күләмен билгели торган норматив, мең сумнарда;

Всв — элемтә буенча хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү вакытын билгели торган норматив, тәүлек.

11. Әлеге Методикада каралган нормативларны федераль башкарма хакимиятнең авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрү өчен җаваплы органы билгели.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып ике ай эчендә аңа туры китерелергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 17 октябре
№ 85-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1032. 2016 елга Татарстан Республикасында муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 17 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә 2016 елга Татарстан Республикасында муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 17 октябре
№ 86-ТРЗ

«2016 елга Татарстан Республикасында муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

## 2016 елга Татарстан Республикасында муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү НОРМАТИВЛАРЫ

1. Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында, компенсацияләү төрендәге мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының гадәти төркемнәрендә, катнаш төрдәге мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативлары

| Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының атнасына эш көннәре саны | Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының эш сәгатьләре саны | Җирлек (округ) | Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына сумнарда/бер тәрбияләнүчегә | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | бер үк яшьтәге төркемнәр | | | төрле яшьтәге төркемнәр | | | гаилә мәктәпкәчә мәгариф оешмалары төркемнәре |
| | | | 2 айдан алып 1 яшькә кадәр | 1 яшьтән алып 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр | 2 айдан алып 3 яшькә кадәр | өч төрле яшьтә-геләр: 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр | ике төрле яшьтәгеләр: 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр | |
| 5 эш көне | 3 | шәһәр | 11744 | 10686 | 10026 | 15777 | 15712 | 10026 | - |
| | | авыл | 12647 | 11421 | 10607 | 16943 | 16744 | 10607 | - |
| | 4 | шәһәр | 17430 | 13529 | 12869 | 21462 | 21397 | 12869 | - |
| | | авыл | 18784 | 14490 | 13676 | 23047 | 22881 | 13676 | - |
| | 5 | шәһәр | 20273 | 16372 | 12869 | 27148 | 24240 | 12869 | - |
| | | авыл | 21852 | 17558 | 13676 | 29216 | 25949 | 13676 | - |



| Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының атнасына эш көннәре саны | Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының эш сәгатьләре саны | Җирлек (округ) | Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына сумнарда/бер тәрбияләнүчегә | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | бер үк яшьтәге төркемнәр | | | төрле яшьтәге төркемнәр | | | гаилә мәктәпкәчә мәгариф оешмалары төркемнәре |
| | | | 2 айдан алып 1 яшькә кадәр | 1 яшьтән алып 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр | 2 айдан алып 3 яшькә кадәр | өч төрле яшьтә-геләр: 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр | ике төрле яшьтәгеләр: 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр | |
| | 6 | шәһәр | 23116 | 19214 | 15712 | 29991 | 27083 | 15712 | - |
| | | авыл | 24920 | 20626 | 16744 | 32285 | 29017 | 16744 | - |
| | 7 | шәһәр | 31161 | 20806 | 19748 | 38633 | 35128 | 19748 | 17564 |
| | | авыл | 33417 | 22218 | 21006 | 41378 | 37514 | 21006 | 18757 |
| | 9 | шәһәр | 39689 | 26492 | 22591 | 50004 | 43656 | 22591 | 21828 |
| | | авыл | 42809 | 28481 | 24169 | 53886 | 46906 | 24169 | 23453 |
| | 10,5 | шәһәр | 45374 | 32177 | 25434 | 55689 | 49342 | 25434 | 24671 |
| | | авыл | 48946 | 34618 | 27238 | 60023 | 53043 | 27238 | 26521 |
| | 12 | шәһәр | 51060 | 35020 | 28277 | 64218 | 55027 | 28277 | 27514 |
| | | авыл | 55083 | 37687 | 30306 | 69228 | 59180 | 30306 | 29590 |
| | 24 | шәһәр | 96544 | 66291 | 33962 | 123916 | 60713 | 33962 | 30356 |
| | | авыл | 104177 | 71439 | 36443 | 133664 | 65317 | 36443 | 32658 |
| 6 эш көне | 9 | шәһәр | 45374 | 32177 | 28277 | 58532 | 49342 | 28277 | 24671 |
| | | авыл | 48946 | 34618 | 30306 | 63091 | 53043 | 30306 | 26521 |
| | 10,5 | шәһәр | 53903 | 37863 | 31120 | 67060 | 57870 | 31120 | 28935 |
| | | авыл | 58151 | 40755 | 33375 | 72296 | 62248 | 33375 | 31124 |
| | 12 | шәһәр | 59588 | 40706 | 33962 | 75589 | 63556 | 33962 | 31778 |
| | | авыл | 64288 | 43823 | 36443 | 75866 | 68385 | 36443 | 34192 |
| | 14 | шәһәр | 68117 | 49234 | 39648 | 86960 | 72084 | 39648 | 36042 |
| | | авыл | 73493 | 53029 | 42580 | 93775 | 77590 | 42580 | 38795 |
| | 24 | шәһәр | 116444 | 80504 | 39648 | 146658 | 72084 | 39648 | 36042 |
| | | авыл | 125656 | 86781 | 42580 | 158211 | 77590 | 42580 | 38795 |

2. Гомуми үсеш төрендәге мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативлары

| Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының атнасына эш көннәре саны | Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының эш сәгатьләре саны | Җирлек (округ) | Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына сумнарда/бер тәрбияләнүчегә | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | бер үк яшьтәге төркемнәр | | | төрле яшьтәге төркемнәр | | | гаилә мәктәпкәчә мәгариф оешмалары төркемнәре |
| | | | 2 айдан алып 1 яшькә кадәр | 1 яшьтән алып 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр | 2 айдан алып 3 яшькә кадәр | өч төрле яшьтәгеләр: 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр | ике төрле яшьтәгеләр: 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр | |
| 5 эш көне | 3 | шәһәр | 12491 | 11433 | 11646 | 16524 | 17332 | 11646 | - |
| | | авыл | 13394 | 12168 | 12256 | 17690 | 18392 | 12256 | - |
| | 4 | шәһәр | 18177 | 14276 | 14489 | 22209 | 23017 | 14489 | - |
| | | авыл | 19530 | 15236 | 15324 | 23793 | 24529 | 15324 | - |
| | 5 | шәһәр | 21019 | 17118 | 14489 | 27895 | 25860 | 14489 | - |
| | | авыл | 22599 | 18305 | 15324 | 29963 | 27598 | 15324 | - |
| | 6 | шәһәр | 23862 | 19961 | 17332 | 30737 | 28703 | 17332 | - |
| | | авыл | 25667 | 21373 | 18392 | 33031 | 30666 | 18392 | - |
| | 7 | шәһәр | 31907 | 21553 | 21368 | 39379 | 36748 | 21368 | 18374 |
| | | авыл | 34163 | 22965 | 22655 | 42125 | 39162 | 22655 | 19581 |
| | 9 | шәһәр | 40436 | 27239 | 24211 | 50750 | 45276 | 24211 | 22638 |
| | | авыл | 43556 | 29228 | 25818 | 54633 | 48555 | 25818 | 24277 |
| | 10,5 | шәһәр | 46121 | 32924 | 27054 | 56436 | 50962 | 27054 | 25481 |
| | | авыл | 49693 | 35365 | 28886 | 60770 | 54691 | 28886 | 27346 |
| | 12 | шәһәр | 51807 | 35767 | 29897 | 64964 | 56647 | 29897 | 28324 |
| | | авыл | 55829 | 38433 | 31955 | 69975 | 60828 | 31955 | 30414 |
| | 24 | шәһәр | 97291 | 67037 | 35582 | 124663 | 62333 | 35582 | 31166 |
| | | авыл | 104924 | 72186 | 38091 | 134411 | 66965 | 38091 | 33482 |
| 6 эш көне | 9 | шәһәр | 46121 | 32924 | 29897 | 59279 | 50962 | 29897 | 25481 |
| | | авыл | 49693 | 35365 | 31796 | 63838 | 54691 | 31955 | 27346 |
| | 10,5 | шәһәр | 54649 | 38610 | 32739 | 67807 | 59490 | 32739 | 29745 |
| | | авыл | 58898 | 41502 | 34865 | 73043 | 63897 | 35023 | 31948 |
| | 12 | шәһәр | 60335 | 41452 | 35582 | 76335 | 65175 | 35582 | 32588 |
| | | авыл | 65035 | 44570 | 37933 | 76613 | 70033 | 38091 | 35017 |
| | 14 | шәһәр | 68863 | 49981 | 41268 | 87707 | 73704 | 41268 | 36852 |
| | | авыл | 74240 | 53775 | 44070 | 94521 | 79239 | 44228 | 39619 |
| | 24 | шәһәр | 117190 | 81251 | 41268 | 147405 | 73704 | 41268 | 36852 |
| | | авыл | 126402 | 87528 | 44070 | 158958 | 79239 | 44228 | 39619 |



3. Бала үсеше үзәкләрендә мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативлары

| Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының атнасына эш көннәре саны | Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының эш сәгатьләре саны | Җирлек (округ) | Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына сумнарда/бер тәрбияләнүчегә | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | бер үк яшьтәге төркемнәр | | | төрле яшьтәге төркемнәр | | | гаилә мәктәпкәчә мәгариф оешмалары төркемнәре |
| | | | 2 айдан алып 1 яшькә кадәр | 1 яшьтән алып 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр | 2 айдан алып 3 яшькә кадәр | өч төрле яшьтәгеләр: 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр | ике төрле яшьтәгеләр: 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр | |
| 5 эш көне | 3 | шәһәр | 13238 | 12179 | 12393 | 17270 | 18078 | 12393 | - |
| | | авыл | 14140 | 12915 | 13002 | 18436 | 19139 | 13002 | - |
| | 4 | шәһәр | 18923 | 15022 | 15236 | 22956 | 23764 | 15236 | - |
| | | авыл | 20277 | 15983 | 16071 | 24540 | 25276 | 16071 | - |
| | 5 | шәһәр | 21766 | 17865 | 15236 | 28641 | 26607 | 15236 | - |
| | | авыл | 23346 | 19051 | 16071 | 30710 | 28344 | 16071 | - |
| | 6 | шәһәр | 24609 | 20708 | 18078 | 31484 | 29449 | 18078 | - |
| | | авыл | 26414 | 22120 | 19139 | 33778 | 31413 | 19139 | - |
| | 7 | шәһәр | 32654 | 22300 | 22115 | 40126 | 37495 | 22115 | 18747 |
| | | авыл | 34910 | 23712 | 23401 | 42871 | 39909 | 23401 | 19954 |
| | 9 | шәһәр | 41182 | 27985 | 24958 | 51497 | 46023 | 24958 | 23011 |
| | | авыл | 44303 | 29975 | 26565 | 55380 | 49301 | 26565 | 24651 |
| | 10,5 | шәһәр | 46868 | 33671 | 27801 | 57183 | 51708 | 27801 | 25854 |
| | | авыл | 50439 | 36112 | 29633 | 61516 | 55438 | 29633 | 27719 |
| | 12 | шәһәр | 52553 | 36514 | 30643 | 65711 | 57394 | 30643 | 28697 |
| | | авыл | 56576 | 39180 | 32701 | 70722 | 61575 | 32701 | 30787 |
| | 24 | шәһәр | 98038 | 67784 | 36329 | 125409 | 63079 | 36329 | 31540 |
| | | авыл | 105670 | 72932 | 38838 | 135158 | 67712 | 38838 | 33856 |
| 6 эш көне | 9 | шәһәр | 46868 | 33671 | 30643 | 60026 | 51708 | 30643 | 25854 |
| | | авыл | 50439 | 36112 | 32701 | 64584 | 55438 | 32701 | 27719 |
| | 10,5 | шәһәр | 55396 | 39356 | 33486 | 68554 | 60237 | 33486 | 30118 |
| | | авыл | 59645 | 42248 | 35770 | 73789 | 64643 | 35770 | 32322 |
| | 12 | шәһәр | 61082 | 42199 | 36329 | 77082 | 65922 | 36329 | 32961 |
| | | авыл | 65781 | 45317 | 38838 | 77360 | 70780 | 38838 | 35390 |
| | 14 | шәһәр | 69610 | 50727 | 42015 | 88453 | 74451 | 42015 | 37225 |
| | | авыл | 74987 | 54522 | 44975 | 95268 | 79985 | 44975 | 39993 |
| | 24 | шәһәр | 117937 | 81998 | 42015 | 148151 | 74451 | 42015 | 37225 |
| | | авыл | 127149 | 88274 | 44975 | 159704 | 79985 | 44975 | 39993 |

4. Катнаш төрдәге мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының коррекцияле төркемнәрендә һәм компенсацияләү төрендәге мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының коррекцияле төркемнәрендә мәктәпкәчә белемнең җайлаштырылган уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативлары

| Тәрбияләнүчеләр категориясе | Тәрбияләнүчеләрнең яшь ягыннан составы | Җирлек (округ) | Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белемнең җайлаштырылган уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына сумнарда/ бер тәрбияләнүчегә | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | биш көнлек эш атнасы | | | | | | | | | алты көнлек эш атнасы | | | | |
| | | | көнenә эш сәгатьләре саны | | | | | | | | | көнenә эш сәгатьләре саны | | | | |
| | | | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 9 | 10,5 | 12 | 24 | 9 | 10,5 | 12 | 14 | 24 |
| Сөйләменең бозылган балалар | өч яшькә кадәр | шәһәр | 40418 | 52446 | 66954 | 78981 | 103638 | 120990 | 133385 | 145779 | 244935 | 135864 | 150737 | 165611 | 185442 | 284598 |
| | | авыл | 43267 | 56171 | 71733 | 84637 | 111090 | 129706 | 143003 | 156300 | 262675 | 145662 | 161618 | 177575 | 198850 | 305225 |
| | өч яшьтән өлкәнрәк | шәһәр | 26894 | 34607 | 42319 | 50031 | 65309 | 75225 | 82661 | 90098 | 100014 | 85140 | 92577 | 102493 | 114887 | 114887 |
| | | авыл | 28669 | 36944 | 45217 | 53491 | 69881 | 80519 | 88497 | 96475 | 107113 | 91156 | 99135 | 109772 | 123069 | 123069 |
| Күрү сәләтен өлешчә югалткан балалар (начар күрүчеләр) | өч яшькә кадәр | шәһәр | 40418 | 52446 | 66954 | 78981 | 103638 | 120990 | 133385 | 145779 | 244935 | 135864 | 150737 | 165611 | 185442 | 284598 |
| | | авыл | 43267 | 56171 | 71733 | 84637 | 111090 | 129706 | 143003 | 156300 | 262675 | 145662 | 161618 | 177575 | 198850 | 305225 |
| | өч яшьтән өлкәнрәк | шәһәр | 26894 | 34607 | 42319 | 50031 | 65309 | 75225 | 82661 | 90098 | 100014 | 85140 | 92577 | 102493 | 114887 | 114887 |
| | | авыл | 28669 | 36944 | 45217 | 53491 | 69881 | 80519 | 88497 | 96475 | 107113 | 91156 | 99135 | 109772 | 123069 | 123069 |
| Интеллекты бозылган балалар (акылга зәгыйфьләр) | өч яшькә кадәр | шәһәр | 40418 | 52446 | 66954 | 78981 | 103638 | 120990 | 133385 | 145779 | 244935 | 135864 | 150737 | 165611 | 185442 | 284598 |
| | | авыл | 43267 | 56171 | 71733 | 84637 | 111090 | 129706 | 143003 | 156300 | 262675 | 145662 | 161618 | 177575 | 198850 | 305225 |
| | өч яшьтән өлкәнрәк | шәһәр | 26894 | 34607 | 42319 | 50031 | 65309 | 75225 | 82661 | 90098 | 100014 | 85140 | 92577 | 102493 | 114887 | 114887 |
| | | авыл | 28669 | 36944 | 45217 | 53491 | 69881 | 80519 | 88497 | 96475 | 107113 | 91156 | 99135 | 109772 | 123069 | 123069 |
| Ишетү сәләте бозылган балалар (ишетмәүчеләр) | өч яшькә кадәр | шәһәр | 40418 | 52446 | 66954 | 78981 | 103638 | 120990 | 133385 | 145779 | 244935 | 135864 | 150737 | 165611 | 185442 | 284598 |
| | | авыл | 43267 | 56171 | 71733 | 84637 | 111090 | 129706 | 143003 | 156300 | 262675 | 145662 | 161618 | 177575 | 198850 | 305225 |
| | өч яшьтән өлкәнрәк | шәһәр | 42321 | 54350 | 68857 | 80884 | 105542 | 122894 | 135288 | 147683 | 165035 | 137767 | 152641 | 167514 | 187345 | 187345 |
| | | авыл | 45221 | 58125 | 73686 | 86590 | 113043 | 131659 | 144956 | 158253 | 176869 | 147615 | 163572 | 179528 | 200803 | 200803 |
| Күрү сәләтен югалткан балалар (сукырлар) | өч яшькә кадәр | шәһәр | 40418 | 52446 | 66954 | 78981 | 103638 | 120990 | 133385 | 145779 | 244935 | 135864 | 150737 | 165611 | 185442 | 284598 |
| | | авыл | 43267 | 56171 | 71733 | 84637 | 111090 | 129706 | 143003 | 156300 | 262675 | 145662 | 161618 | 177575 | 198850 | 305225 |
| | өч яшьтән өлкәнрәк | шәһәр | 42321 | 54350 | 68857 | 80884 | 105542 | 122894 | 135288 | 147683 | 165035 | 137767 | 152641 | 167514 | 187345 | 187345 |
| | | авыл | 45221 | 58125 | 73686 | 86590 | 113043 | 131659 | 144956 | 158253 | 176869 | 147615 | 163572 | 179528 | 200803 | 200803 |
| Ишетү сәләтен өлешчә югалткан балалар (начар ишетүчеләр) | өч яшькә кадәр | шәһәр | 40418 | 52446 | 66954 | 78981 | 103638 | 120990 | 133385 | 145779 | 244935 | 135864 | 150737 | 165611 | 185442 | 284598 |
| | | авыл | 43267 | 56171 | 71733 | 84637 | 111090 | 129706 | 143003 | 156300 | 262675 | 145662 | 161618 | 177575 | 198850 | 305225 |
| | өч яшьтән өлкәнрәк | шәһәр | 33917 | 42319 | 53198 | 61600 | 81943 | 94337 | 101774 | 111689 | 124084 | 104253 | 116647 | 126563 | 141436 | 141436 |
| | | авыл | 36204 | 45217 | 56889 | 65901 | 87726 | 101023 | 109001 | 119638 | 132935 | 111660 | 124957 | 135595 | 151551 | 151551 |



| Тәрбияләнүчеләр категориясе | Тәрбияләнүчеләрнең яшь ягыннан составы | Җирлек (округ) | Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белемнең җайлаштырылган уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына сумнарда/ бер тәрбияләнүчегә | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | биш көнлек эш атнасы | | | | | | | | | алты көнлек эш атнасы | | | | |
| | | | көнenә эш сәгатьләре саны | | | | | | | | | көнenә эш сәгатьләре саны | | | | |
| | | | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 9 | 10,5 | 12 | 24 | 9 | 10,5 | 12 | 14 | 24 |
| Терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар | өч яшькә кадәр | шәһәр | 40418 | 52446 | 66954 | 78981 | 103638 | 120990 | 133385 | 145779 | 244935 | 135864 | 150737 | 165611 | 185442 | 284598 |
| | | авыл | 43267 | 56171 | 71733 | 84637 | 111090 | 129706 | 143003 | 156300 | 262675 | 145662 | 161618 | 177575 | 198850 | 305225 |
| | өч яшьтән өлкәнрәк | шәһәр | 33917 | 42319 | 53198 | 61600 | 81943 | 94337 | 101774 | 111689 | 124084 | 104253 | 116647 | 126563 | 141436 | 141436 |
| | | авыл | 36204 | 45217 | 56889 | 65901 | 87726 | 101023 | 109001 | 119638 | 132935 | 111660 | 124957 | 135595 | 151551 | 151551 |
| Туберкулез интоксикациясе булган балалар | өч яшькә кадәр | шәһәр | 24990 | 32704 | 40416 | 48127 | 63406 | 73321 | 80758 | 88195 | 147688 | 83237 | 90673 | 100589 | 112984 | 172477 |
| | | авыл | 26716 | 34990 | 43263 | 51538 | 67928 | 78566 | 86544 | 94522 | 158347 | 89203 | 97181 | 107819 | 121116 | 184941 |
| | өч яшьтән өлкәнрәк | шәһәр | 19186 | 23501 | 30296 | 34611 | 43991 | 51427 | 56385 | 61343 | 68780 | 56385 | 63822 | 68780 | 76216 | 76216 |
| | | авыл | 20398 | 25030 | 32318 | 36950 | 47011 | 54989 | 78923 | 65626 | 73604 | 60307 | 68286 | 73604 | 81583 | 81583 |
| Еш авыручы балалар | өч яшькә кадәр | шәһәр | 24990 | 32704 | 40416 | 48127 | 63406 | 73321 | 80758 | 88195 | 147688 | 83237 | 90673 | 100589 | 112984 | 172477 |
| | | авыл | 26716 | 34990 | 43263 | 51538 | 67928 | 78566 | 86544 | 94522 | 158347 | 89203 | 97181 | 107819 | 121116 | 184941 |
| | өч яшьтән өлкәнрәк | шәһәр | 19186 | 23501 | 30296 | 34611 | 43991 | 51427 | 56385 | 61343 | 68780 | 56385 | 63822 | 68780 | 76216 | 76216 |
| | | авыл | 20398 | 25030 | 32318 | 36950 | 47011 | 54989 | 60307 | 65626 | 73604 | 60307 | 68286 | 73604 | 81583 | 81583 |
| Катлаулы дефектлары булган балалар | өч яшькә кадәр | шәһәр | 48127 | 63551 | 69061 | 94400 | 124981 | 144813 | 159686 | 174559 | 293546 | 162165 | 179517 | 199348 | 221658 | 340645 |
| | | авыл | 51538 | 68086 | 84631 | 101179 | 133987 | 155262 | 171219 | 187175 | 314826 | 173878 | 192494 | 213769 | 237703 | 365354 |
| | өч яшьтән өлкәнрәк | шәһәр | 50031 | 65455 | 80880 | 96304 | 126885 | 146716 | 161590 | 176463 | 295450 | 164068 | 181421 | 201252 | 223562 | 223562 |
| | | авыл | 53491 | 70039 | 86584 | 103132 | 135941 | 157216 | 173172 | 189128 | 210403 | 175831 | 194447 | 215722 | 239657 | 239657 |
| Сөйләмендә фонетик-фонематик җитешсезлекләре булган балалар | өч яшьтән өлкәнрәк | шәһәр | 23037 | 30288 | 35061 | 42313 | 55865 | 63301 | 70738 | 75696 | 83132 | 70738 | 78175 | 85611 | 95527 | 95527 |
| | | авыл | 24530 | 32310 | 37432 | 45211 | 59749 | 67727 | 75705 | 81024 | 89002 | 75705 | 83683 | 91662 | 102299 | 102299 |
| Сәламәтлек мөмкинлекләре башкача чикләнгән балалар | өч яшькә кадәр | шәһәр | 24990 | 32704 | 40416 | 48127 | 63406 | 73321 | 80758 | 88195 | 147688 | 83237 | 90673 | 100589 | 112984 | 172477 |
| | | авыл | 26716 | 34990 | 43263 | 51538 | 67928 | 78566 | 86544 | 94522 | 158347 | 89203 | 97181 | 107819 | 121116 | 184941 |
| | өч яшьтән өлкәнрәк | шәһәр | 19186 | 23501 | 30296 | 34611 | 43991 | 51427 | 56385 | 61343 | 68780 | 56385 | 63822 | 68780 | 76216 | 76216 |
